ПИОНЕР КАЛӘМЕ

МАЙ 1940 №5

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!
ЛЕНИН—СТАЛИН ЭШЕ ӨЧЕН КӨРӘШКӘ ХӘЗЕР БУЛ!

ПИОНЕР КАЛӘМЕ

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ. ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ ОРГАНЫ.

БУ НОМЕРДА:

Май шатлыгы (Фоат Кәримов шигыре) 2
Большевистик матбугат бәйрәме (мәкалә) 3
Кояш һәм бала (Ш. Маннур шигыре) 4
Руслан һәм Людмила (А. С. Пушкин әсәре, Ә. Исхак тәрҗемәсе) . . . 5
Альп таулары аша (С. Глязер мәкаләсе) 9
Болыт (Мәхмүт Хөсәенев шигыре) 12
Урманда (Нурулла Шәрифуллин шигыре) 12
Калкукырда кар беткәч (Мирсәй Әмир хикәясе, П. Новичков рәсемнәре) 13
Үткен егет (Хәй Вахит әкияте, Б. Баһаветтинов рәсемнәре) 20
Почта маркасына 100 ел 22
Сания (Мөнҗия Гилфанова хикәясе) 25
Шүрәле (Художник Г. Арсланов рәсме) 29
Укучыларыбыз сөйли (журнал турында фикерләр) 30
Даһи рус композиторы (Җәүдәт Фәйзи мәкаләсе) 31

Тышлыкның беренче битендә: художник П. Новичков монтажы,
өченче битендә: күңелле ял.

Редакциянең адресы: Казан шәһәре, Бауман урамы, 19.
Матбугат йорты (2 нче кат, 5 нче бүлмә).
Телефон № 18—78.

МАЙ 1940 № 5



Сталин исмендәге автозаводның (Москвада) 12 нче номерлы балалар бакчасында. РӘСЕМДӘ: балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр Ленинның тормышы һәм эше турында язылган китап укыйлар.
Фото—В. Зунин. (ТАСС фотоклишесе).

МАЙ ШАТЛЫГЫ

Май кояшы көлә зәңгәр күктә,
Һәр тарафтан хуш ис бөркелә.
Шат халыклар тавышы белән бүген
Туган илем шаулый, гөр килә.

Тагын бер кат зур тантана белән
Каршыладык бөек бәйрәмне.
Урамнардан җырлап узабыз без
Җилфердәтеп кызыл әләмне.

Шатлык ташый дәртле йөрәкләрдән
Язгы ташкыннан да ким түгел.
Алгы җиңүләргә ашкына һәм
Канатлана безнең яш күңел.

Фоат Кәримов.
Молотов өлкәсе.

Большевистик матбугат бәйрәме

„Керосин лампасы белән яктыртылган кысынкы бүлмә. Кечкенә генә түгәрәк өстәл янында Сталин язып утыра. Аннан якын гына урында типография станогы куелган. Станок янында эшчеләр эшли... Хәрефләр шырпы һәм папирос тартмаларына, кәгазьләргә салынган. Иптәш Сталин үзе язган бер кәгазьне эшчеләргә бирә. Мин һәм Коция еш-еш ишек алдына чыгабыз һәм төнге тынлыкта тирә-якны сак кына күзәтәбез, тыңлыйбыз. Ниһаят, Сталин язып бетерде. Урыннан торды да язылганны безгә укыды. Прокламация тексты безнең һәрберебезгә дә гаят зур тәэсир итте“.

Батуми шәһәрендә подпольедәге большевистик типографиянең эше турында революционерларның берсе әнә шулай дип яза. Эшчеләргә хакыйкатне сөйләү өчен, самодержавиегә каршы көрәшнең юлларын күрсәтү өчен ялкынлы листовкалар бастырырга кирәк иде. Полиция шымчыларыннан яшеренеп, басу станокларын һәм хәрефләрне большевикларга бер урыннан икенче урынга күчереп йөртергә туры килде.

Большевистик редакцияләр Бөек Октябрь Социалистик революциясе көннәренә кадәр әнә шулай эшләделәр.

Кешелекнең бөек даһие Владимир Ильич Ленин матбугатка югары бәя бирде, халыклар юлбашчысы Иосиф Виссарионович Сталин аңа югары бәя бирә.

Царизм елларында Ленин һәм Сталин большевистик матбугатның беренче оештыручылары булдылар. 1912 нче елның 5 нче маенда Петербургта алар большевистик газета—„Правда“ны чыгаруны оештырдылар.

Газета эшчеләр арасында бик тиз авторитет һәм мәхәббәт казанды. Эшчеләр аны уку белән генә чикләнмәделәр, аның актив ярдәмчеләре дә булдылар. „Правда“ның беренче 99 номерында эшчеләрнең 1783 хаты урнаштырылды. Алар аңа үзләренең авыр тормышлары турында, царизмга каршы көрәшләре турында яздылар.

Эшчеләр үзләренең сөекле газеталарыннан бер вакытта да аерылмадылар. Алар Кышкы дворецны штурмлауга „Правда“ белән бардылар, революцион эшчеләр Бөек Октябрьнең казанышларын „Правда“ белән сакладылар.

Хәзер безнең җирдә үзгәрешләр күп. Безнең ватаныбыз—бөтен дөньяда иң куәтле социалистик дәүләт. Коммунистлар партиясенең сугышчан газетасы—„Правда“—совет кешеләренең иң сөекле газетасы.

Советлар илендә төрле телдә 9000 газета чыгарыла. Аларда хезмәт ияләре үзләренең тормышлары турында язалар. Коммунистлар партиясе безнең ватаныбызның миллионнарча хезмәт ияләрләре белән газета аша сөйләшә. Большевиклар кулында газета коммунизм өчен көрәштә иң үткен һәм иң көчле корал булып тора.

Совет халкы „Правда“ газетасының беренче номеры чыгу көнен бәйрәм итеп,—большевистик матбугат көне итеп билгеләде.

Безнең илебездә шулай ук уннарча балалар газетасы чыгарыла. Аларның иң алдынгысы булган „Пионерская правда“ газетасына быел 15 яшь тулды.

Яшь пионерлар һәм укучылар өчен иптәш Сталинның: „Яхшы! Молодец, балалар!“ дигән мактавыннан да югары мактау юк. Балаларның газеталары һәм журналлары Ватанны һәм иң кадерлебезне, иң сөекле дустыбызны шатландырырга үзләренең укучыларын чакырдылар һәм чакыралар. Алар яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү буенча мактаулы бурычны үтәү өчен киләчәктә дә большевикларча эшләрләр.

Совет халкы Ленин һәм Сталин исемнәре белән җиңде, җиңә һәм җиңәр!

КОЯШ ҺӘМ БАЛА

Ш. Маннур

Бала әле татлы йокысында,
Ә кояш инде күптән
Елмая тәр тәрәзә турысында;
Кулларын суза күктән.
Чәчләреннән сыйпый ул баланың:
„Тор инде, дустым, тор, ди,
Битләреңне юып, һәм таранып,
Чәй эчәргә утыр!“—ди.
Китапларын букчасына салып,
Чыкса урамга бала,
Кояш аны култыгыннан алып,
Мәктәпкә кадәр бара.

Атлап бала мәктәп баскычларын,
Шаян уйларын өзә.
Һәм сайлый ул белем ачкычларын,
Ә кояш күктә йөзә.
Ишеккә ул башын сыйдыралмый,
Хәтере кала шуңар.
Ә мәктәпкә керми булдыралмый
Сибәргә якты нурлар.
Әйләнә дә, тәрәзәләр аша
Бүлмәләргә керә ул,
Һәр балага йомшак караш ташлап,
Елмаеп өлгерә ул.
Иркәләнеп ала, песи кебек,
Ауный өстәл өстендә.
„Уңайсызлама!—ди бала көлеп,—
Ят син тәрәзә төбендә“.
Озакламый бетә дәресләрем.
Кайтырбыз тагын бергә.
Мин карармын бераз өй эшләрен,
Син утырырсың түрдә“.

Тәрәзәдән кояш китә тып-тын,
Тик яулык болгый аңа.
Әнкәсенең кушкан эшен онтып,
Урамга чыга бала.
Алар тагын икәү бергә уйный,
Гөрләвектә гөрләшеп.
Кояш карны камчы белән кыйный,
Кар түгә кайнар яшен.
Ә бала ул көмеш гөрләвекнең
Юлларын ачып йөри:
„Гөрләш, серләш инде, юлың иркен,
Бар, түбәнгә йөгер!“—ди.
Яр башында гөбердәвек шаулый,
Анда ул ясый арык.
Кар суларын барсын шунда каулый
Һәм куя нәни чарык.
Карап тора да ул, көлеп куя,
Әйләнә чарык һаман.
Кояш аңа энҗе нурлар коя,
Уйный күбәләксыман.
Аякларын суга чыландырып,
Кайта бала җилпенеп.
Кояш кала күзен моңландырып,
„Кирәсеңме инде?“—дип.

Кайта да ул дәфтәрләрен ала,
Дәресен карый башлый.
Кояш тагын ян тәрәздән аңар
Соңгы нурларын ташлый:
„Сау бул инде, дустым!“ дигән
кебек,
Еракка китә һаман.
Күк читләрен алтын белән күмеп,
Югала аска табан.
Карап торгач бала, исе китеп,
Бу ялкын болытларга;
Дәресләрен укып, тәмам итеп,
Килеп ята йокларга.
Бала әле татлы йокысында,
Ә кояш инде күптән
Елмая түр тәрәзә турысында;
Нурларын сибә күктән.

IV—40.



А. С. Пушкин

Руслан һәм Людмила

Рус халкының бөек шагыйре Александр Сергеевич Пушкин безгә гаят күп санда гүзәл әсәрләр язып калдырды. Аның бу әсәрләрен—роман, поэма, хикәя һәм шигырьләрен татарчага тәрҗемә итү һәм шулай итеп, аларны татар хезмәт ияләренең дә уртак әдәби байлыгына әвереләдерү буенча соңгы елларда күп кенә эшләр башкарылды. Соңгы вакытта А. С. Пушкинның зур әсәрләреннән тагын берсе—„Руслан һәм Людмила" поэмасы татарчага тәрҗемә ителде һәм ул быел басылып чыгачак.

„Руслан һәм Людмила" поэмасы А. С. Пушкинның иң беренче зур әсәрләреннән берсе булып тора. Фантастик әкиятләргә нигезләп язылган бу әсәрдә, ул—Киев кнәзе Владимирның (X нчы йөз ахырлары) кече кызы Людмила белән аның сөйгәне, рус батыры Русланның башыннан кичкәннәре турында сөйли. Батыр Руслан үзенең кәләше Людмиланың явыз, сихерче кәрлә Черномор тарафыннан урлануыннан соң, аны эзләргә чыгып китә. Ул бик күп көрәшләрдән соң, гаят зур кыенлыклар белән, Людмиланы сихерче Черноморның тоткынлыгыннан коткара. Аңар үзенең юлында гаят зур бер башка очрарга һәм аның белән сугышып, аны җиңәргә туры килә.

Без журналыбызның бу номерында поэмадан әнә шул баш белән Руслан арасында булган сугыш турындагы өзекне урнаштырабыз.

Тын йокыга талган җир өстендә
Алсу шәфак инде югалды;
Күтәрелде алтын ай да менә,
Дулкынланып күксел томанны;
Дала тынды. Кара сукмак буйлап
Китте Руслан төрле уйлар уйлап;
Һәм күренде аңар шул чакта
Томанланып зур тау еракта;
Хырылдады нидер шунда тагын.
Тауга таба китте ул алга;
Ә серле тау якын барган саен,
Сулаган күк булды Русланга.
Алга карый Руслан һич куркусыз,
Тыныч кына итеп, калтыраусыз;
Тик аткае тери аякларын,
Калтырана, чигә аннары;
Торгыза ул куркып колакларын,
Үрә тора аның яллары.
Ул тау кинәт шунда яктыра да
Томан аша айның нурында,
Ачыклана: Руслан карый аңа —
Чын могҗиза тора алдында.
Табармынмы сүзләр язарга?
Тере бер баш күренә аңарга!
Зур күзләрен баскан йокы аның,
Хырлый, селкеп шлем каурыйларын,
Иөри алар башның очында,
Күләгәдәй, томан эчендә.
Һәм дәһшәтле бер матурлык белән
Күтәрелеп моңсу киң кырда
Бу исемсез сакчы, тынлык белән
Чолганган да, Руслан каршында.
Охшап куркынычлы бер тауга,
Тора шунда чумып томанга.
Хәйран калып карый аңа Руслан,
Уятырга тели йокысыннан.
Якын килде һәм әйләнеп чыкты,
Гаҗәплеген карап ул аның,
Сүзсез генә аннан кытыклады
Сөңге белән башның танавын;
Каш җыерып шуннан баш иснәде,
Зур күзләрен ачты, төчкерде...
Купты давыл, тузан күтәрелде,
Бөтен дала тетрәп селкенде;
Керфекләрдән, мыек һәм кашлардан
Очып чыкты бик күп ябалак,
Төчкергәне башның урманнардан
Кире кайтты бик нык яңгырап.
Бу тавыштан аты куркып китте,
Пошкырды да, кинәт кире чикте,
Чабып китте артка нык кына,
Егылмады батыр чак кына.
Ишетелде тагын тавыш шунда:
„Ни эшлисең, егет, бу ни хәл?
Мин шаярмыйм, әйдә, бул юлыңда!
Мин йотармын юкса, әй наһал!"

Күз салды да Руслан як-ягына,
Атын тартты ныклап тезгеннән
Һәм елмайды карап магрур гына:
„Ни телисең, егет, син миннән?—
Дип кычкырды ул баш ачуланып,—
Нинди кунак миңа бит килде!
Кит тизерәк, сүзгә колак салып!
Хуш! Йоклыйсым килә, төн инде!“
Данлы батыр ләкин башның шунда
Җавап итеп тупас сүзенә,
Ачу белән олысымак кына:
„Тукта, буш баш!—диде үзенә,—
Мин ишеткән туры бер сүз бар:
Маңгае киң, ләкин мие тар!
Сикертермен атым, тик сызгырмам,
Сикереп менсәм ләкин ычкындырмам!“

Ярсуыннан тәмам телсез калып,
Ачу белән чиксез калтыранып,
Баш бүртенә шунда, кабара;
Ялтырыйлар күзләр нак ут кебек,
Иреннәре кала күбекләнеп,
Бар җиреннән парлар чыгара.
Кинәт кенә аннан бөтен көчкә
Өрә башлый сулыш ул егеткә;
Ә ат исә, йомып күзләрен,
Иеп башын, киереп күкрәген,
Кара төндә давыл, яңгыр аша
Юкка гына ыргытыла башка;
Сукыраеп, куркып, калтырап,
Хәлдән таеп, тәмам аптырап,
Омтыла ул кырга китәргә,
Тели анда бер ял итәргә.
Руслан тагын һөҗүм итмәк була,
Тик һөҗүме кире кайтарыла,
Өмет бетә! Ә баш котырып,
Көлә аннан бик нык кычкырып:
„Айһай, егет, батыр икәнсең син!
Тукта әле кая китәсең син?
Юкка, батыр, алай куркасың,
Акрынрак, муйның сынмасын;
Бетмәс борын атың эштән чыгып,
Минем дә тап күңлем, берәр сугып!“
Шул арада озын телен сузып,
Баш котырта безнең егетне;
Иөрәгенә бар ачуын йотып,
Суза аңа Руслан сөңгене,
Иркен тотып көчле кулларында;
Корыч сөңге кинәт кенә шуннаң
Телгә барып бик нык кадала.
Котырынган башның авызыннан
Елга булып менә кан ага.
Гаҗәпләнү, ачу, авыртудан
Кыюлыгы башның югала.
Сөңге чәйнәп, агарынып шуннан,
Егеткә ул карап тын кала.

Нак шулай ук безнең сәхнәбездә
Кай вакытта Мельпоменаның[1]
Начар бер шәкерте ишетә дә
Кемнәрнеңдер сызгырганнарын,
Тынычлыгын җуя, дулкынлана,
Күрү көчен кинәт югалта,
Түбән ия башын, калтырана,
Агарына, ролен оныта,
Тотлыга һәм туктый ул шунда,
Шаулап көлгән халык каршында.
Торганлыгын башның хайран калып
Күргәннән соң, шуннан файдаланып,
Оча егет, гүя карчыга;
Салмак кулын аннан югарыга
Күтәрә дә башның яңагына
Бик нык кына итеп бер суга;
Яңрап китә тавыш бөтен җиргә;
Якындагы чыклы үләннәр дә
Кызыл канга кала буялып;
Тора да баш бераз чайкалып,
Бер кырыйга авып китә шунда,
Чуен шлем төшә шалтырап.
Элек ул баш торган буш урында
Зур бер кылыч ята ялтырап.
Шатлыгыннан Руслан калтырап,
Шул кылычны ала уң кулына
Канлы үлән буйлап баш янына
Чабып китә: менә ниятләнә
Колак-борнын башның чабарга;
Ул сугарга инде хәзерләнә,
Һәм кизәнә менә аңарга—
Туктап кала ләкин күреп аның
Бик кызганыч итеп ялварганын...
Ул төшерә кулын акрын гына,
Йөрәгендә аның ачу тына,
Тәэсирләнеп шунда ялварудан,
Кими башлый үч тә аңарда,—
Нак җиңелеп кояш нурларыннан
Эрегән күк бозлар кырларда.

„Акыл бирдең, батыр, миңа,—диде,
Авыр сулап аңар баш шунда.—
Синең кулың миңа исбат итте:
Мин гаепле синең каршыңда;
Моннан ары сиңа буйсынам мин,
Ләкин, егет, мәрхәмәтле бул син!
Кызганырлык минем язмыш бик.
Батыр егет идем мин дә бит!
Дошман белән канлы сугышларда
Тиң чыкмады миңа бер кем дә.
Энем миңа дошман булмаганда,
Калмас идем мин дә бу көнгә!

1. Мельпомена—борынгы грекларда трагедия алласы. Бу урында актер мәгнәсендә кулланыла.



Син сәбәпче барлык бәләләргә,
Син, Черномор, явыз, ач җанлы!
Хурлык булып безнең семьябезгә,
Кәрлә килеш туып сакаллы,—
Кече яштән минем төз гәүдәмә
Көнләмичә карый алмадың,
Шуның өчен явыз йөрәгеңдә
Зур дошманлык миңа сакладың.
Бер катлырак идем мин һәр вакыт,
Зур булсам да: ә ул, ул бәдбәхет,
Шул буй белән җен күк акыллы,
Өстәвенә гаҗәп мәкерле.
Шуны әйтим сиңа мин тагын да:
Аның гаҗәп шушы сакалында

Шомлы бер көч кереп яшренгән,
Бар нәрсәне дошман күргән хәлдә,—
Сакалына зарар килмәгәндә,
Курыкмый ул җирдә бер кемнән.
„Тыңла, диде миңа, хәйлә белән,—
Ул дусларча итеп бер чакны,—
Баш тартма, син, диде, хезмәтеннән;
Укып белдем кара китапны:
Көнчыгышта, тауларның артында,
Бер диңгезнең тынсу ярында,
Тын подвалда, йозак асларында
Бер кылыч бар—дәһшәт, бел, шунда
Мин тикшереп белдем сихер белән!
Язмышларның явыз ирке белән

Билгеләнгән безгә ул кылыч:
Безнең өчен ул бик куркыныч!
Ул кисәчәк минем сакалымны,
Синең башны; белсәң син әгәр,
Явыз рухлар куйган ул кылычны
Табу кирәк безгә никадәр!“—
„Нәрсәдә соң моның кыенлыгы?
Мин барырмын,—дидем кәрләгә,—
Кырыена хәтта бу дөньяның“...
Бер наратны салдым җилкәгә,
Киңәш өчен бер җилкәмә тагын
Явыз җанны, аны утырттым;
Ерак җиргә шулай юл тоттым.
Үч иткәндәй явыз бу язмышка,
Шөкер булсын, эш шәп барды башта;
Озак баргач, үтеп без тауларны,
Килеп чыктык диңгез янына,
Җимердем мин шомлы ул подвалны
Һәм кылычны алдым кулыма.
Ләкин язмыш миңа тагын сукты:
Арабызда безнең талаш купты!
Беләсеңме нәрсә турында?
Кылыч тиеш кемгә булырга?
Мин талаштым, кәрлә кызып китте,
Тарткалаштык озак без гаять;
Ул явыз җан мәкерлеген итте,
Йомшаган күк булды ниһаять.
„Ташлыйк, диде, бушка талашуны,—
Йомшак кына итеп ул шунда.—
Пычратабыз болай без дуслыкны,
Акыл куша тату булырга.
Кемгә тиеш кылыч?—без такдиргә
Хәл итәргә моны тапшырып,
Колак куеп ятыйк икәү җиргә
(Ниләр тапмый уйлап явызлык!),
Иң беренче тавыш кем ишетсә,
Кылыч булыр мәңге шуңарга“.
Диде дә ул шулай, ятты җиргә,
Мин дә яттым, җүләр булганга.
Ятам җирдә, бер ни ишетмим,
Алдаларга үзен исәплим!
Алданганмын үзем бик нык кына:
Шул тынлыкта теге явыз җан,
Басып килеп аяк очларына,
Бер кизәнде минем артымнан:
Үткен кылыч җилдәй сызгырынды,
Караганчы ләкин артыма,
Гәүдәсеннән башым аерылды—
Әллә нинди серле көч шунда
Яшәү көчен башның саклап калды.
Гәүдәм минем ерак чит илдә,
Шул көенчә күмелмичә торып,
Череп бетте тәмам онтылып,
Чәнечкеле үлән эчендә.
Явыз кәрлә ләкин мине аннан
Алып кайтты шушы якларга,
Һәм куйды ул, хәзер сиңа калган,
Шул кылычны мәңге сакларга.
Ал син, батыр, аны кулыңа,
Язмыш саклар, юнәл юлыңа!
Туры килеп, кәрлә сихерчене
Бер очратсаң әгәр алда син,
Мәкерлеге, явызлыгы өчен
Үч алмыйча аннан калма син!
Бу дөньядан тынычлап күчәрмен
Мин бәхетле булып шул чакта,
Рәхмәт укып сиңа, онытырмын
Сукканыңны минем яңакка.

Ә. Исхак тәрҗемәсе.



Быел 18 нче майда бөек рус полководецы Александр Васильевич Суворовның үлүенә 140 ел тулды. РӘСЕМДӘ: А. В. Суворов (1800—1940 ел).

АЛЬП ТАУЛАРЫ АША

Урта диңгездән алып, Карпат тауларының итәгенә һәм Дунай елгасы коя торган урынга кадәр, гигант кыядан торган дуга шикелле булып, Альп таулары сузылганнар. Бик күп батыр гаскәрләр бу тауларның итәгенә җиткәч, аңа штурм ясаудан куркып, тукталып кала торган булганнар. Карфагенның бөек полководецы Ганнибал гына беренче булып Альп таулары аша үткән. Аның армиясе, тарихта беренче булырак, кеше менә алмаслык тауларны 15 көн эчендә үтеп чыккан. Атлы һәм җәяүле гаскәр белән бергә карфагенлыларның 37 сугышчан филләре дә шушы таулар аша үткәннәр.

Бу эш безнең эрага кадәр 218 нче елда була. Шуннан соң ике мең ел үтә. Һәм җиңелмәс рус гаскәрләре бөек полководец Александр Васильевич Суворов җитәкчелегендә беренче булып Альп таулары аша чыгалар. Бу героик эшләре белән Суворов һәм аның батыр солдатлары бөтен дөнья хәрби сәнгате тарихының онтылмаслык сәхифәләрен яздылар.

Фридрих Энгельс моны: „Альп таулары аша булган переходларның иң күренеклесе",—дип атады.

Рус солдатларының батырлыгын, әйтерсең, табигат үзе сынап карамакчы булды. Бозлавык, теп-текә кыялар, карга күмелгән тау башлары, төбе күренми торган чокырлар, ул урыннар белән таныш булмау, киемнең һәм ашамлыкның җитмәве, каршыдагы тәҗрибәле дошман—менә болар барсы да тау аша үтү эшен бик кыенлаштырдылар.

Римский - Корсаков җитәкчелегендәге рус отряды белән кушылу өчен иң

кыска юл Сен-Готард тавы аша ята. „Болан үтәрлек урыннан солдат үтә ала, ә солдат үтәрлек урыннан бөтен бер гаскәр үтә алачак“.—Суворовның кагыйдәсе әнә шундый була.

Беренче көчле сугыш Шәйтан күпере янында була. Күпергә якын да килеп булмый, тар сукмаклар буенча үтәргә теләгән кыю егетләр французлар тарафыннан юк ителәләр. Шул чак 300 кеше дошманның артына төшәргә һәм аны урнашкан урыннан куып чыгарырга теләкләрен белдерәләр. Бу батырлар текә кыялардан үрмәләп, Рейсс елгасының шаулы ташкыны аша үтеп, таштан-ташка сикереп, дошманның тылына барып керәләр. Аларның килеп чыгулары французлар өчен һич тә көтелмәгән хәл була һәм алар кача башлыйлар. Ләкин французлар чигенгән вакытта ташкынлы Рейсс елгасы аша салынган бердән-бер күперне—Шәйтан күперен җимерәләр. Бәхеткә каршы, күпердән ерак түгел генә урында иске бер сарай була. Рус солдатлары шул сарайны җимереп, такта һәм бүрәнәләрне үзләренең шарфлары белән бер-берсенә бәйләп, күперне рәтлиләр һәм елганың аръягына чыгалар.

Французлар чигенгәндә юлларындагы барлык күперләрне яндыра баралар. Рус гаскәрләренең алдынгы отрядлары ялкын эчендәге күпергә кереп, үз иптәшләре чыгар юлны саклап калу өчен барлык көчләрен куялар, утны сүндерәләр.

1799 нчы елның 16 нчы сентябрендә, иртән сәгат 5 тә рус гаскәрләре карлы Росшток тавына менә башлыйлар. Тау сукмагы шундый тар, хәтта ул берәмләп үтү өчен дә куркынычлы. Кешеләр юлны артык дәвам иттерергә көчләре җитмичә, шашынып туктыйлар. Суворов үзенең гаскәренең я алдына чыга, я артка кала. Солдатларның хәлдән таюларын күргәч ул:

„Ни булды кызга?

Ул матур кызга“—дип җыр башлап җибәрә. Кешеләргә дәрт кереп китә, аннан соң алар үзләре дә җырга кушылалар.

Ниһаят, алар тауның башына менеп җитәләр. Ләкин аннан төшү, менүгә караганда да, куркынычлырак була. Барсының да итекләре ертылып, эштән чыгып бетә. Солдатларның аякларында чолгаулар гына кала. Хәтта генераллар да табан асларын мундир сукнолары белән урыйлар.

Росшток тавын төшеп җиткәч, Суворовка кайгылы хәбәр китерәләр. Рус гаскәрләренең Римский-Корсаков җитәкчелегендәге корпусы французлар тарафыннан туздырыла, ә Суворов гаскәрләре аңар кушылырга тиешле иде.

Хәл гадәттән тыш кискен була. Элек уйланганча, Швицка бару инде бер төрле дә нәтиҗә бирмәячәк. Француз генералы Массенаның 60 мең гаскәре бар. Ә рус гаскәрләренең саны егерме меңгә дә тулмый. Кирегә китү—чигенү дигән сүз, ә руслар бер вакытта да чигенмәделәр. Бар өмет бер генә нәрсәдә: гаскәрләрнең батырлыгында, үзләрен үзләре аямауларында.

Суворов хәрби советта үзенең речен болай дип бетерә:

— Безнең алда бик зур эш, дөньяда моңа кадәр тиңе күрелмәгән зур эш тора. Без төпсез чокыр янында, ләкин без руслар...

Солдатлар җавап бирәләр:

— Сиңа үзебез һәм бөтенебез өчен ант бирәбез. Безгә нәрсә генә очраса да, бездә рус кешесенә хас булмаган явыз куркаклыкны, мыгырдануларны син, атабыз, күрмәссең. Каршыбызга йөз меңнәрчә дошманнар чыксыннар. Менә бу таулар өч мәртәбә, ун мәртәбә кыенрак шартлар тудырсыннар—без барыбер тегеләрен дә, боларын да җиңүчеләр булып чыгарбыз!

Бу сүзләрне тыңлаганнан соң бөек полководец үзенең гаскәрләренә Римский-Корсаков гаскәрләре урнашкан Глариска барырга дип приказ бирә. Французлар Суворовны үзенең гаскәре белән тауларда һәлак булды дип ышаналар һәм шуңа күрә алар оборонага да хәзерләнмиләр. Сан ягыннан күп булуга да карамастан, француз гаскәрләре чигенәләр.

Рус солдатларына соңгы тауны—Рингекопф тавы аша чыгарга туры килә. Суворов аурый башлый. Ике казак аның атын тезгененнән тотып алып ба-

ралар. Гаскәрләр тау башына менеп җиткәч, түбәнгә төшә торган урында бозлы текә яр булуын күрәләр. Түбән төшү өчен яраклы бер төрле дә сукмак юк. Ярдан түбәнгә шуып төшәргә дигән уй кинәт берсенең башына килә. Солдатлар һәм офицерлар мылтыкларын кысып тоткан килеш, бозлы яр буйлап төпсез тирәнлеккә бер-бер артлы шуалар. Күбесе һәлак була, күбесе гарипләнә. Ләкин алар җиңәләр. Таулар, бозлар һәм карлар аша дошман чолганышын өзеп, батыр армия Иланц авылына килеп җитә. Анда ул бик күп азык запаслары таба. Газаплар онтыла, Суворов ярата торган сугышчан рус җырлары тагын яңгырый башлый.

Француз генералы Массена Суворовның Альп таулары аша уңышлы үтеп чыгуы турында болай ди:

— *Мин әнә шушы бер переход өчен генә дә үземнең 48 переходымны бирер идем!*

Суворовка рус армиясе генералиссимусе исме бирелә. Дөньяның бөтен газеталары рус армиясенең Альп аша уңышлы переход ясавы турында алкышлап язалар. Солдатлар тарафыннан мәхәббәт казанган Суворовның исән-сау кайтуына бары тик рус патшасы Павел I генә шатланмый. Ул үзе тарафыннан армиягә кертелгән таяк дисциплинасын Суворов җимерер дип курка. Бөтен кеше тарафыннан Суворовны олылаулар, хөрмәтләүләр көтелгәндә, Павел I Суворов янындагы барлык адъютантларны чакырып алырга, аңар бары тик төнлә генә Петербургка керергә рөхсәт итеп приказ бирә.

Авыру Суворов Петербург чигендә торучы туганына кайтып урнаша. Бу эш 1800 нче елның 20 нче апрелендә була, ә инде шул ук елның 18 нче маенда Суворов үлә. Аны күмүдә сановниклардан һәм патша сарае кешеләреннән берәү дә катнашмый. Берәү дә аның кабере өстендә речь сөйләми. Суворовны яратучы, аңар бәя бирүче кешеләр генә аның гәүдәсен озатырга киләләр. Алар тирән тынлык саклап таралалар.

Моннан 140 ел элек рус халкының батыр улы, бөек полководец Александр Васильевич Суворов менә шулай үлә. Совет халкы аны хөрмәтләп искә ала һәм аның батырлыклары белән горурлана.

С. Глязер.



Болыт

Карап торам күзем төбәп
Мин күкнең йөзен,
Аксыл болытлар куерта
Һава диңгезен.
Көнчыгыштан акрын гына
Бер болыт йөзә,
Шул вакыт минем күзләрем,
Аңарга төшә:

— Әйтче, болытым, матурым,
Кайлардан килдең?
Нинди калаларны үттең,
Юлда ни күрдең?
Булдыңмы, зинһар сөйләче!
Кытай илендә?
Азатлык сөйгән дусларның
Туган җирендә?
Һәм күрдеңме газ, төтенле
Сугыш кырларын,
Ишеттеңме халыкларның
Ирек җырларын?
„Тыңла“,—дигән кебек булды
Шунда ак болыт,
Якынлашты да кереште
Сүзгә шатланып:

— „Әгәр белсәң дусларыңның
Бөек җиңүен,
Йөзләрең синең елмаер,
Сөенер күңлең.
Кытай иле чәчәк атыр,
Якты көн килер,
Бәхет кояшы да аңа
Котлап нур сибер“.

Гүя, шулай җавап бирде
Миңа ул болыт,
Һәм көнбатышка урныннан
Китте кузгалып,
— Рәхмәт сиңа, мине чиксез
Шатландырганга,
Хуш бул!—диеп яулык болгап
Калдым аңарга.
Минем сөекле болытым
Күздән югалды,
Тик аның миңа сөйләгән
сүзләре калды.

Мәхмүт Хөсәенев.
Петропавловск шәһәре.

—★—

Урманда

Яшеллеккә төренгәннәр
Таллар, имәннәр.
Ак каеннар ботакларын
Түбән игәннәр.

Яшел хәтфә юрган япкан
Җирнең өстенә,
Урман чумган чәчәкләрнең
Тәмле исенә.

Сары, чуар күбәләкләр
Уйнап очалар;
Яшел, кызыл чәчәкләрне
Сөеп кочалар.

Урман матур, урман ямле,
Урман күңелле!
Ашкындыра, үзенә тарта
Безнең күңелне.

Дәрестән соң матур итеп
Җырлап уйнарга,
Бергәләшеп без киләбез
Ямле урманга.

Нурулла Шәрифуллин.
Бондюг районы, Песәй авылы.



Калкукырда кар беткәч*

(„Батыр исемле малай турында хикәяләр“ сериясеннән).

Мирсәй Әмир — *П. Новичков рәсемнәре*

XIV.

Батыр тирә якка күз салды. Тилереп аккан елгадан башка нәрсә күренмәде. Күптән түгел генә кар астыннан чыккан былчырак язгы юл, ташландык аркан кебек, хәрәкәтсез иде. Батыр ямансылый башлады. Ул үзенә-үзе кызганыч тоелды. Аның күзенә яшләр килде...

Кояш шактый түбәнәйгән, кичке салкын җил исә башлаган иде инде.

— Шулай ук миңа шушы тирәк башында кунарга туры килер микәнни?— Батыр тирән сулап куйды.—Юк, монда куну мөмкин түгел, монда туңып үләрсең... Ни эшләргә соң? Ул агачка якынрак булган уң як ярга карады. Яр ерак түгел. Ләкин анда чыгу өчен бик күп көч кирәк иде.—Йөзеп чыга алырмынмы, юкмы?—дип уйлады Батыр. Тик үзенә үзе ышанмыйча, тагын тирән итеп көрсенде.—Юк, булдыра алмам, йөзү ягына килгәндә мактарлык җирем юк. Мондый салкын су, мондый каты агым! Юк, шарламак астына төшәрмен дә китәрмен, кыен булса да шушы агач башында утыру яхшырак булыр. Борынгы халыклар гел агач башында торганнар, ди... Борынгы халык!.. Кояшны да алла дип белгән, болытны да алла дип белгән вәхши халык! Минем соң шул вәхшиләрдән алдын җирем юкмыни? Юк, миңа монда калырга ярамый, миңа бурычымны үтәргә кирәк.

Шундый уйлар астында борчылып, тынычсызланган Батыр тагын суга карады. Өметсезләнеп, яңадан агач ботакларын тикшерә башлады. Аның күзләре кинәт үрмәкүч авына туктaлдылар.

Югарыга күтәрелгән бер ботактан су өстенә таба асылган озын пәрәвез җебенә ябышкан бер чүп кисәге җилгә тирбәнеп тора иде. Батыр, шул пәрәвез җебенә карап каткан хәлдә, бераз вакыт хәрәкәтсез торды да, кинәт җанланып китте. Тиз генә оекларын киеп алды, бер кулы белән ботакка тотынып, икенче ботак өстенә тәпи басты. Аннан соң аркасы белән тирәкнең үзегенә сөялде дә, чалбар каешын ычкындырып алды һәм мәче җитезлеге белән югарыга—тирәкнең башына күтәрелде. Иң оч-

*, Ахры. Башы журналның 3,4 нче номерларында.

тан аерылып ярга таба сузылган ботак буенча үрмәләде. Чайкалып торган ботак өстеннән ярны күзәтте:

— Була, була,—дип куйды ул. Каешның пряшкәле башын бик нык итеп ботакка беркетте һәм куллары белән каешка асылынып, түбән төшә башлады. Ул ярга таба сузылган иң биек ботактан асылынып тирбәлергә, шулай итеп ярга сикерергә план корган иде. Шул эшнең уңышлы барып чыгачагына ышанып, каешның очына хәтле төште. Даган атынгандагы хәрәкәтләрен файдаланып, аякларын селкетте һәм шактый кызу итеп атына башлады. Ботакның селкенеп торуы аның атыну көчен арттыра төште. Ярга чыгу өмете якынайганнан якынайды. Тик, андый вакытта бәлә өстенә бәлә чыгып торучан була бит. Инде яхшылап атынып киттем, сикерергә көч алдым дигәндә генә, Батырның каешсыз калган чалбары төшә башлады. Куллар икесе дә барлык көчкә каешка ябышкан булганлыктан, төшеп барган чалбарны һич ничек тә тотып калу мөмкинлеге юк иде. Чалбар, башта акрынрак, соңга таба кызулабрак төшә барып, тәмам аяк очына кадәр сыерылды. Батырның ике аягы да үз чалбары белән тышауланып калды. Бу хәлдән котылу өчен Батыр яңадан ботак өстенә күтәрелергә уйлады. Тик аякны тышаулап өлгергән чалбар яңадан күтәрелергә ирек бирмәде. Аптырагач, шул хәлдә сикерергә уйлады. Тик батырлыгы җитмәде. Белеп булмый бит, ярга барып җитә алмыйча суга төшсәң, чалбарыңа уралып егылырсың да, шарламак астына төшеп китәрсең!.. Тышаудан котылу өчен чалбарны бөтенләй суга төшереп җибәрүдән башка чара юк иде. Батыр озак баш ватмады:

— Чалбар кыйбатмы, баш кыйбатмы?—диде дә, аякларын селкетеп, чалбарны төшереп җибәрде. Тилереп аккан су, шуны гына көтеп торган төсле, ашыга-ашыга чалбарны шарламак астына алып төшеп китте. Чалбардан котылгач, Батыр тагын да җиңеләя төшеп тирбәлде. Беләк мускулларын барлык көченә киереп чайкалды да, ярга ташланды. Бил тиңентен суга барып төшсә - төште—ярга чыкты. Шул минутта ул, гомерендә беренче мәртәбә, күлмәгенең озын булуына шатланды. Юк исә ул һәр вакытта әнисенә үпкәләп, күлмәген озын итеп теккән өчен ачуланып йөри иде. „Миңа күлмәкне озын итеп текмә, кыска итеп тек“,—дип әнисенә ялына торган иде. Тик әнисе аның сүзен тыңламый: „Син үсәсе кеше, кендеге күрнеп йөргән малайларны яратмыйм мин“,—дип Батырның күлмәген озын итеп, тездән итеп тегә иде. Бу мәсьәләдә әнисен җиңә алмаган Батыр, итәген чалбар эченнән калдырып киеп кенә күлмәкнең озынлыгыннан котыла иде.

Куркынычлы шарламак өстендә ыжылдап утырган ялгыз тирәк ботагына асылынган хәлдә, ярга сикерергә азапланган минутта, Батыр тик үзен-үзе коткару уе белән генә мавыгып, районга эш белән барасын оныткан иде. Исән-сау килеш ярга чыгу белән аның төп эше исенә төште төшүен, тик бераз гына соңгарак калган иде инде.

— Эшләр харап!—дип кычкырып җибәрде ул һәм аз гына да уйланып тормастан, елга буйлап түбәнгә таба чаба башлады.

Районга илтеп тапшырырга тиешле пакет шарламак астына төшеп агып киткән чалбар кесәсендә иде.

XV.

Агып киткән чалбар артыннан елга буйлап йөгергәндә Батырга төрле юллардан үтәргә туры килде. Әле—аякны тартып ала алмаслык булып бата торган пычрак ерырга, әле—эреп бетмәгән кар аркылы йөгереп чыгарга, әле—кар астыннан чыгып кибәргә дә өлгергән чирәм өстеннән чабарга туры килә иде аңар. Батыр аяк астында нинди җир булуга әһәмият бирми, тынычсызланган күзләре белән өзлексез рәвештә елга өстен күзәтә, су өстен чуарлаган бозлар арасын җентекли иде.

Шактый озак йөгергәннең соңында, ул елганың нак уртасында агып баручы бер кара әйберне күрде:

— Шул, шул,—дип куйды Батыр,—чалбардан башка әйбер булуы мөмкин түгел. Тик аны ничек тотарга?

Киң булып җәелгән ташкынның уртасында агып барган чалбарны ничек тә тоту мөмкинлеге күренми иде. Батыр чабу темпын кызулата төште һәм бик тиз арада чалбар турысыннан узып, алга китте. Ничек тә алгарак барып, берәр уңаерак урында чалбарны кулга төшерү

чарасын күрергә кирәк,—дип уйлый иде ул.

Йөгерә торгач, бер урында елганың яры биегәеп китте. Батыр зур гына калку өстенә барып чыкты. Калку өстендә зур сөргән җир иде. Батыр үз колхозларының җирен күптән узып киткән иде инде. Аның башында: күрше колхозның да җире чәчәрлек булган инде, дигән уй чагылып узды. Ул арада, Батырдан ерак түгел, җир өстеннән бик күп сыерчыклар төркеме күтәрелде. Батыр „болар да чәчә башлады микән әллә“ дигән уй белән җир өстенә җентекләбрәк күз салып алды. Җир өстенә бодай чәчелеп, тырмаламыйча калдырылган иде. Сыерчыклар төркеме шул җиргә сибелгән орлыкны рәхәтләнеп чүпли бирә икән. „Моны онытмаска кирәк“ дип куйды Батыр. Тагын бераз йөгергәч, ул шул ук сөргән җирнең икенче ягынарак тугарылып калдырылган тырмалар һәм шуннан ерак түгел бер тезмә чәчү машинасы күрде. Тырмалар һәм машина тирәсендә бер нинди дә җан иясе күренми иде. „Моны да онытырга ярмый,—дип уйлады Батыр, эшләгәннәр дә икән, кич булгач, коралларын кырда калдырып кына кайтып киткәннәр икән“.

Кояш баеды. Батырның алдына озакламый караңгы төшү куркынычы килеп басты. Әгәр дә караңгы төшеп китсә, чалбар күздән югалачак. Аннары аны бөтенләй табып булмаячак. Чалбарны көтеп алып эләктерерлек уңайлы урын очрамый да—очрамый. Батыр йөгерә дә, йөгерә... Ни эшләргә?

XVI.

Тәмам аптыраштa калдым, чалбарны тотудан өметне өздем дигәндә генә, алда елга аркылы салынган таза күпер күренде. Бу күрше авыл күпере иде. Батыр бөтен өметен шул күпердә генә күреп, тизрәк күпергә җитәргә ашыга башлады.

Күпер елга өстеннән шактый биек итеп, язгы ташкыннарда да агып китмәслек итеп салынган булса да, Батырның бәхетенә каршы, ташкын көчле булганлыктан, су күпергә бик якын күтәрелгән булып чыкты. Ныграк сузылганда су өстендә агып барган әйберне кул белән дә үрелеп алырлык иде. Батыр күпер өстенә менде, постка



Иптәш Мирсәй Әмир.

куелган сакчы төсле, әрле-бирле йөреп, чалбар килеп җиткәнен көтә башлады.

Шул минутта аның хәтеренә колхоз председателе Бәкернең әйткән сүзләре килеп төште. Бәкер абзый миңа шушы күпер аркылы барырга кушкан иде бит, туп-туры шушы юлдан киткән булсам, бик күп булса ярты сәгать эчендә килеп җиткән булыр идем. Ә миңа, елга уңаена борыла-борыла, агач башы саен туктый-туктый, ярты сәгатьлек юлны көн озынына үтәргә туры килде. Җитмәсә чак үлми калдым. Иң хурлыклысы: өстемә йөкләнгән бурычны яхшы итеп үти алмадым. Әле чалбарны тотаммы, юкмы, тоткан сурәттә дә пакет юешләнеп, танымаслык хәлгә килгән булуы мөмкин... Әни белеп әйтә шул: „Олылар сүзен тотмаган, олыгайганчы игелек күрмәгән“, ди...

Ул шундый уйларны башыннан кичерә-кичерә, чалбарны өзлексез күзәтә, тирә-якта ни бар, ни югын күрми иде.

Чалбар озак көттермәде, килеп җитте, Батыр күпер өстенә аркылы ятып, ярты гәүдәсе белән үк сузылды һәм чалбарны эләктерде.

Нак шул минутта аны берәү уң ягыннан тотып алды:

— Ни эшлисең, малай актыгы, суга төшеп китәсең бит, ни эшләп йөрисең монда, бу вакытта, кем син?

Батыр, чалбарны эләктерү шатлыгыннан кәефле елмаеп, аяк үрә басты һәм артында торган кара сакаллы кешегә борылып җавап бирде.

— Менә чалбар тоттым.

Кара сакаллы кеше бер нәрсә дә аңламады:

— Ничек ул алай, елгадан чалбар оталармыни? Балыкмыни ул чалбар?

Батыр башыннан үткәннәрне кыскача гына сөйләп бирде һәм үзенең хәзер районга барырга ашыкканлыгын әйтте. Кара сакаллы кеше күрше колхозның председателе булып чыкты. Ул ат җигеп район үзәгенә барырга чыккан икән. Күпер өстендә Батыр азапланганны күргәч, тарантаска җигелгән күк атын елга кырыенда калдырып, үзе күпергә кергән икән.

— Син тәмам туңып, эштән чыккансың бит,—диде ул Батырга һәм үз алдына үзе сөйләгән тавыш белән „Тәмле елга“ колхозының председателе Бәкергә ачулана башлады:

— Председателегезне әйтер идем, бу кадәр башсыз, ахмак кеше булыр икән. Бала белән исәпләшмәгән өчен судка бирү аз ул шәйтанны.

Батыр Бәкер абзыйсын якларга азапланып карады:

— Бәкер абзый гаепле түгел,— диде,—мин үзем гаепле, аның сүзен тыңламыйча, җимерек күпер аркылы киттем.

— Әйдә, әйдә, күп сөйләнмә,—диде күрше колхоз председателе.—Әйдә, утыр тизрәк, туңып беткәнсең!

— Юк, мин туңмадым,—диде Батыр, һаман карышты. Ләкин теше-тешкә бәрелүдән аның туңганлыгы күренеп тора иде. Шуңар күрә дә күрше колхоз председателе аны коры тотты.

— Әйдә тиз бул, утыр тарантаска!

Батыр, артык сөйләнмәде, районга тиз барып җитәм икән дип шатланып, тарантас өстенә менде. Кара сакаллы председатель аның белән янәшә утырып, дилбегәсен какты. Ул районга бара торган булса, хәзер күпер аркылы чыгып китәргә тиеш иде. Ләкин ул алай эшләмәде, атны кире артка борып, үз колхозларына таба юырттыра башлады. Бу хәлне күргәч, Батыр утырган урыныннан сикереп торды:—„Миңа районга барырга кирәк“,—дип арбадан сикерергә җайланды, ләкин председатель аны җибәрмәде. Итәгеннән тотып кире утыртты:

— Ашыкма, өлгерербез,—диде ул.— Бу килеш син бит туңып үләрсең. Хәзер безнең өйгә кереп, җылынып, тамак ялгап, киемнәреңне алмаштырып чыгарсың. Шуннан бергәләп китәрбез.

Батыр эндәшмәде. Барыбер кичектем инде дигәндәй, председательнең сүзләренә риза булып утырды.

XVII.

Батыр район үзәгенә килеп җиткәндә шактый соң булып, колхоз өйләренең күбесе йокыга чумган булсалар да, район җир бүлегендә ут бар иде. Ишектән кергәч тә уң яктагы өстәлдә счет салып утыручы яш кеше алдына килеп басты Батыр. Счет салучының бераз бушаганрак минутын көтеп, эндәшми торды. Теге кеше башын күтәргәч кенә кулындагы пакетны сузды. Өстәл янында утыручы кеше гаҗәпләнде: бер—карага буялып, бозылып беткән пакетка, бер — Батырга карап, беразга сүзсез калды, аннан соң кызыксынган тавыш белән Батырга сорау бирде:

— Син каян?

— „Тәмле Елга“ колхозыннан.

Җир бүлеге работнигы башка сорау бирмәде, урыныннан кузгалып, стенага беркетелгән телефон янына килде. Аны шыгырдатып борды. Телефон чылтырап куйды.

— Райком секретаре иптәш Галинны бирегез.

Телефон тагын борылды, тагын чылтырады.

— Иптәш Галинмы? Исәнмесез. Теге малай килде... Әлеге „Тәмле Елга“ колхозыннан... Әйе... Ярый, яхшы...

Җир бүлеге кешесе телефон трубкасын элеп, отбой бирә-бирә, Батырга сорау куйды:

— Райкомны беләсеңме?

— Беләм.

— Пакетыңны алып хәзер шунда бар. Иптәш Галин үз янына чакыра сине.

Бәкер килеп, бер пионерның югалган хәбәрен әйтеп киткәннән соң, райком секретаре Галин тиз генә тынычлана алмады. Югалган пионерның исме ничек булуын да белмәвенә карамастан, үз баласын югалткан кебек хафалана башлады. „Табылдымы икән. Яхшылап эзләү эшен оештырдыларммы икән, шуларны белеп кайт“ дип бер комсомолецны „Тәмле Елга“ колхозына җибәрде. „Ул колхоздан кем килсә дә миңа җибәрегез“ дип, район җир бүлегенә әйтеп куйды. Шул сәбәпле, җир бүлегеннән телефон шал-

тырап „Тәмле Елга“ колхозыннан килгән малай турында хәбәр иттеләр. Галин зур һәм бик кирәкле кешене көткән сыман, дулкынланып, малайның килгәнен көтә башлады. Телефоннан хәбәр иткәнгә биш минут та вакыт узмады, башына зур козыреклы соры кепка, өстенә зур гына бишмәт, аякларына зур күн итек кигән, киң чалбарлы малай— Батыр килеп керде (бу киемнәрне аңа әлеге кара сакаллы председатель биреп торган иде).

Галин аны якты, ягымлы чырай белән каршы алды:

— Әйдүк, егет, кил якынрак.

Батыр нәрсә дип тә әйтергә белмичә, әкрен генә атлап, өстәл янына килде. Өстенә кызыл материя ябылган өстәлнең читенә тотынды.

— Я, егет, каян килдең? Исмең ничек?

— Мин җир бүлегенә „Тәмле Елга“ колхозыннан бер пакет алып килгән идем, исмем Батыр.

—Ә — ә, Батыр. Ни эшләп болай төнгә калдың?

— Сез, Галин абый, миңа ачуланмагыз инде, икенче тапкыр болай эшләмәм. Бәкер абый каян йөрергә кушса, шуннан йөрермен, үземнең ялгышканымны үзем дә аңладым инде.

— Тукта, тукта, зарланырга ашыкма, мин сине ачуланырга җыенмыйм,—диде Галин,—ни эшләп болай соңга калдың дип кенә сорыйм?

Батыр иркен сулап, көрсенеп куйды.

— Юлда азрак уңайсызлык килеп чыкты.

— Нинди уңайсызлык, я, сөйләп бир әле.

— Тәмле елганы чыккан вакытта күпер җимерелде.

— Я, я, шуннан?

Шулай „я, я“ дип торып, Галин Батырның юл буена күргән нужаларын баштан аяк сөйләтеп чыкты. Аннан соң „Тәмле елга“ колхозында ниләр барлыгы, уку эшләренең ничек баруы турында сораштты. Батыр, Галин тарафыннан бирелгән сорауларның һәммәсенә диярлек, тулы итеп, ачык итеп җавап кайтарып торды. Пионерларның колхоз эшендә ничек актив катнашуларын сөйләп бирде. Аның күңеле күтәрелгәннән күтәрелә бара иде.

Батыр үзенең башыннан үткәннәрне сөйләгәндә, Галин аның геройлыгына сокланып, эчтән шатланып утырды: „Үсә төшкәч ниләр эшләмәс бу малайлар?! Бу зирәклек, бу батырлык, бу йөрәклелекләр өстенә, белем белән дә кораллансалар, кояшны, болытларны буйсындырырлык кеше булмаслармыни?“ Ләкин бу уйлар аның күңелендә генә калдылар. Галин аларны Батырның үзенә әйтмәде. „Үз алдында ук болай мактарга иртә булыр, укысын әле“— дип уйлады ул. Шулай да, малайның күңелен күтәрерлек дәрәҗәдә генә мактау сүзе әйтергә дә саранланмады.

— Һу, һу, молодец, егет икәнсең, бер нәрсәдән дә курыкмыйсың, сиңа Батыр исеме әрәм түгел.

— Эштәп курыккан юк инде ул, Галин абый.

— Эштән курыккан юк дисеңме, шулай кирәк, шулай. Ә, Батыр дус, беләсеңме соң син, синең үзеңнең төп эшең нәрсә?.

Батырга бу сорау көтелмәгәнрәк булып чыкты.

— Ничек төп эш?

— Менә синең иң беренче чиратта эшләнергә тиешле эшең, эшләнми калырга ярамый торган эшең нәрсә?

Батыр бераз уйланып торганнан соң, үзен олыларча гына тотып, мондый җавап бирде:

— Вактына карап төрле эш була инде. Менә хәзер язгы чәчүгә актив татнашу, ярдәм итү.

— Ярый, ә менә быел кыш буена эшләргә тиеш булган төп эшең нәрсә иде, моннан соң, быел, киләсе ел... кыскасы, үсеп зур кеше булып җиткәнче эшләргә тиешле төп эшең нәрсә, шуны беләсеңме?

Аптыраштан күзләре зур булып ачылган Батыр әкрен генә җавап бирде:

— Социализм төзү.

Галин тагын елмая төшеп:

— Социализмны барыбыз да төзибез. Тик социализм төзүчеләр һәр кайсы үзләренә берәр эш алып баралар бит. Алып карыйк менә бер колхозны: кырчылык бригадасында эшләүчеләрнең төп эшләре кырда эшләү—чәчү, уру, җыю, сугу, күп уңыш алу; яшелчәләр бригадасының төп эше—яшелчә үстерү; төзүчеләр бригадасында эшләүчеләрнең төп эше—кирәкле каралтылар төзү; терлекчелек фермасында эшләүчеләрнең



Каганович исмендәге колхоздагы "мәктәптә" (Бохара районы, Үзбәкстан ССР) рус теле һәм әдәбияты дәресендә. Укытучы комсомолец Хәйдәр Мәхмүтов „Юлбарыс тиресе ябынган батыр" дигән поэма буенча занятие алып бара. Аның янында укучылардан Ташбиби Салихова һәм Сәет Сабиров.

Фото—**И. Юсупов.** (ТАСС фотоклишесе).

төп эше—терлекләрне карау, аларны үрчетү. Алар һәммәсе дә үз эшләрендә җаваплылар, үз эшләренең ударниклары булырга тырышалар. Үзенең төп эшендә ударник булган кеше—социализм төзүдә иң актив эшче. Менә синең үзеңнең төп эшең нәрсә?

Батыр башын түбән иде, һәм оялып кына елмайды:

— Мин бит әле, Галин абый, кечкенә. Мин әле укыйм, минем андый төп эшем юк.

— Укыйсыңмыни син?

— Ни эшләп укымаска. Бездә бөтен балалар укый.

— Дәресләреңне яхшы беләсеңме соң?

— Нигә белмәскә, укыгач беләсең инде. Нәрсәсе бар аның.

— Менә шул укуың—синең төп эшең түгелмени?

— Бездә бит хәзер каникул вакты.

— Каникул бит ул ял вакты гына, ул тагы да яхшырак итеп уку өчен кирәк, һәрбер эштә дә шулай, аргач азрак ял итеп алалар да, тагы да тырышыбрак эшли башлыйлар.

— Шулай инде.

— Шулай булгач, үзеңнең төп эшең нәрсә икәнен беләсеңме инде?

— Уку.

— Әйе, Батыр дус, сезнең төп эшегез уку. Шуны бер вакытта да онытма. Колхоз эшенә булышу бик яхшы. Тик ул синең төп эшеңә, укуыңа зыян китермәсен, укуыңа аз гына зарар китерә торган булса да, синең колхозга булышуыңнан файда юк. Ни чаклы яхшы укучы булсаң, социализм төзүдә шул чаклы яхшы катнашучы буларсың. Шуны исеңдә тот. Мәктәбеңдә сине яхшы укучы ударник дисәләр, чәчүләр беткәч, Казанга алып барырбыз үзеңне. Ударниклар съездына барасың киләме?

Батыр бу сорауга җавап бирә алмады. Кызарып, башын түбән иде. Ә күңеленнән ул үзен Казан шәһәрендә итеп күрә иде инде.

XVIII.

Батыр, райком бүлмәсеннән чыккач, Галиннең киңәше буенча, район газетасы редакциясенә барды. Хәбәрләр язып торучы булганга, аны редакциядә беләләр иде. Төн буена гөрләп эшли торган редакция, типогрфия кешеләре аны кунак итеп каршы алдылар. Ашаттылар, эчерттеләр һәм, хәзер төн инде, кайтып йөри алмассың дип, үзләре янында кунарга калдырдылар Газетаның ничек җыелуын, ничек басылуын күрү Батыр өчен сөйләп бетерә алмаслык шатлык булды. Ул шунда ук ике хәбәр язып бирде. Хәбәрләрнең берсе чәчеп калдырылган орлыкны сыерчыклар чүпләве, алай эшләмәскә кирәклеге турында, икенчесе—иген коралларын кырда калдырып йөрергә ярамау, дөнья йөзендә Трантай шикелле зарарлы кешеләр йөргән вакытта, һәр эштә саклык кирәклек турында иде. Хәбәрләр аның күз алдында җыелдылар, күз

алдында ук басылып чыга башладылар.

Көн буена күп нужалар күреп арган булуына карамастан, Батырга бүген алган тойгылары йокларга ирек бирмәделәр. Аның әллә ниләр эшлисе, әллә ниләр тудырасы килде.

— Шигырь язам!—диде ул үз алдына үзе. Кулына кәгаз-каләм алды да, бер аулак өстәлгә барып утырды. Типографиядәгеләрнең үзара сөйләшүләре дә, өзлексез гөрләп торган машина тавышы да аңар ишетелмәс булдылар. Озынча итеп киселгән ап-ак кәгаз өстенә „Төп эш“ дигән сүзне язып куйган килеш уйга чумган иде Батыр. Аның башында райком секретаре Галин әйткән сүзләр кабатлана. Ул сүзләр көчәяләр, күз алдына искиткеч зур, искиткеч матур күренешләр китерәләр иде.

Җир йөзендә яшәп килә бик күп кеше,
Һәрберсенең үзенә бар бер төп эше...

Шул ике юлны язды да, туктады Батыр... Тагын нәрсә дип язарга?

„Һәрбер пионерның да төп эше бар, ул төп эш—уку“ дип әйтәсе килде аның. „Ленин бабай безгә укырга кушкан, безнең алда торган иң төп эшләрнең беренчесе дә уку, икенчесе дә уку, өченчесе дә уку“ дип әйтәсе килде. „Без ничаклы яхшы укысак, социализм төзүдә шул чаклы яхшы катнашучы булырбыз“ дип әйтәсе килде. Берсеннән-берсе көчле, берсеннән-берсе матур хыяллар килде аның башына, ләкин ул аларны ничек итеп көйгә салырга, ничек итеп берсенә-берсен ятыш китереп әйтергә белми аптырады.

— Ничек итеп ятыш китерергә соң аны,—дип куйды ул.

Аңар җавап урнында тышкы ишек ачылып китте дә, райком секретаре Галин һәм Батырның этисе Нигмәтҗан абзый белән колхоз председателе Бәкер килеп керделәр.

(Бетте).

Үткен егет

(Халык әкияте буенча)

Хәй Вахит

Б. Баһауттинов рәсемнәре

Кара урман янында,
Тауда—Идел ярында,
Җәелеп яткан бер авыл,
Бик зур авыл булган ул...
Авылның бер башында,
Чүп чокыры каршында,
Иске, җимерек өйдә
Яшәгән тату көйгә
Карт белән карчык бергә,
Ялчы булып гомергә.
Авыр эштә чагында,
(Ачлык ел кочагында)
Үлгән карчык та, карт та,
Өч малай калган йортта...

Малайларның олысы—
Иң таза буынлысы,
Ялланган эшкә байга,
Бер тәнкә белән айга.
Һәр эшне эшләгән ул,
Каршы сүз дәшмәгән ул.
Тик бай һаман тиргәгән,
Һич тынычлык бирмәгән.
Түзмәгән ул, биш айдан
Чыккан да киткән байдан...

Көч кайнаган канында
Уртанчы малайның да,
Үскән ул көчле булып,
Абыйсы төсле булып.
Ул да ялланган байга,
Бер тәнкә белән айга.
Каршы сүз дәшмәгән ул,
Бар эшне эшләгән ул.

Аны да бай тиргәгән,
Һич тынычлык бирмәгән.
Җафа чиккән көн саен,
Ул да ташлаган баен...

Малайларның кечесе,
Кечесе—иң көчлесе,
Батыр булып, бер булып,
Матур булып, ир булып,
Буйга җиткән—зурайган,
Корыч төсле ныгайган.
Үткен булган ул егет,
Батыр арыслан кебек.
Ул да шул байга килгән:
— Мине эшкә ал,—дигән,—
Тик алдан ук килешик,
Килешик, кул бирешик:
Бар сүзеңне тыңларым,
Акча сорап тормамын,
Бер эшкә дә карышмам!
Тик син мине орышма!
Әгәр мине орышсаң,
Орышсаң-кычкырышсаң,
Телеңне кисәрмен, бай,
Килешү булсын шулай!
Мин дә эшкә карышсам,
Яки сине орышсам,
Телемне кисәрсең, бай!
Килешү булсын шулай!
Шул сүздән уйга батып,
Бай торган озак вакыт.
Ялчы кирәген уйлап,
Уйлап, җайлап—уңайлап
Егеткә кул биргән ул,

Килешү белдергән ул.
Шул көннән башлап егет,
Байда йөргән ат җигеп,
Ташыган ул йөген дә,
Чәчкән җиргә иген дә...

Көннәрнең берендә бай
Егеткә әйткән болай:
— Беләмсең зур басуны,
Сукалап кайт бар шуны!
Менә икмәк—бер бөтен,
(Кисмәгәннәр бер читен)
Үзеңә дә, атка да,
Ашатырсың эткә дә...
Тик ипи кайтсын бөтен!
Җирне сукалап бетер!..
Алсуланган таң белән,
Таң белән—чулпан белән,
Эт ияртеп, ат җигеп
Киткән сукага егет,
Ул тиз барып җиткән дә,
Сукага ат җиккән дә,
Тирли-тирли җир сөргән.
Эт тә ияреп йөргән,
Йөргән, йөргән дә өргән.
Һәм егет аңа биргән
Икмәкнең фәкат эчен,—
(Байны алдалар өчен
Башта икмәк ярган ул,
Аннан эчен алган ул).
Егет тагын эшләгән,
Кашка ат та кешнәгән,—
Егет икмәк йомшагын
Атка ашаткан тагын.
Егет тагын эшләгән,
Төш тә җиткән эш белән
Егет икмәк йомшагын
Үзе ашаган тагын.
Сука беткәч, ат җигеп
Кайтып та киткән егет.
Бик тиз кайтып кергән ул,
Байга илтеп биргән ул,
Бөтен икмәк кабыгын...
Бай сизгән эче югын.—
Алданганын аңлаган,
Тик орыша алмаган,
(Барсын да хәтерләгән,
Тел кисүдән шүрләгән).

Икенче көн таң белән,
Таң белән чулпан белән,
Егетне чакырган бай,
Һәм бойрык биргән болай:
— Менә бер көтү сарык,
Күлле болынга барып,
Шул көтүне егет син,
Көзгә каәрле көт син!
Бел,—үзеңә ашарга,
(Көзгә кадәр яшәргә)
Суярсың җиткәч барып,
Беренче көнне сарык.
Кайсы сиңа караса,
Шунысын суй да аша!“
Егет болынга киткән,
Сарык көтүен көткән.
Болын үләнле булган,
Күңелле, ямле булган...
Егет план корган да,—
Болынга чакырган да
Җир сөрүче халыкны,
Суйган унбиш сарыкны.
Ярлы халык берләшеп,
Биеп, җырлап, гөрләшеп,
Ит ашаган болында,
Болында—күл буенда.
Ярлы халык гөрләшеп,
Биеп, уйнап, җырлашып,
Сарык суеп көн саен,
Каршылаган көз аен...
Көз җиткән, көн кыскарган,
Җиналган иген кырдан,
Яуган беренче кар да,
Җилләр сызгырган кырда,
Көннәр дә салкынайткан...
Егет баена кайткан.
Көтүне сораган бай,
Егет сөйләгән болай:
— Үтәдем син әйткәнне,—
Мине җибәргән көнне:
„Кайсы сарык караса,
Бәйлә дә, суй да аша
Шул сарыкны“,—диден бит,
Бойрык биргән идең бит.
Суярга пычак алсам,
Көтүгә күзем салсам,
Миңа таба бар сарык
Карап тора күз салып.
Синең сүзне тотып, бай,
Барсын да суйдым шулай...“
Бай бармагын шартлаткан,—
Булган эшкә шак каткан,
Кыскан ачудан тешен,
Кызып үзгәрткән төсен.
Алданганын аңлаган,
Тик орыша алмаган,—
(Барсын да хәтерләгән,
Тел кисүдән шүрләгән).

Егет күргән шул чакта,
Бай хатыны почмакта,
Әзерләгән барын да:
Әлбәсен дә, балын да,

Тәлинкәдә каз ите,
Табасында котлеты;
Паштит куелган тагын,
Бигрәк бай булган табын,
Егет кызыгып торган,
Бай барган да утырган.
Ашаган чагында бай,
Егеткә әйткән болай:
— Бар, син егет, икмәк из!
Хәзер үк из—тиз бул, тиз!
Арыш оны амбарда,
Читтә—капчыкта, ларда!
Шулчак, ашамый барган
Егет әлеге амбарга.
Тик аңа он иләргә,
Аннан икмәк изәргә,
Булмаган иләге дә,
Һәм куас чиләге дә...
Бер фикер килгән аңа,
Тозны салган да онга,
Якындагы коега ул,
Лардан онны койган ул.
Изәргә дә юл белгән,
Изгән ул сиртмә белән...
Бай бармагын шартлаткан,—
Булган эшкә шак каткан,
Тагын үзгәрткән төсен,
Кыскан ачудан тешен.
Алданганын аңлаган,
Тик орыша алмаган,—
(Барсын да хәтерләгән,
Тел кисүдән шүрләгән).

Икенче көнне ул бай
Егеткә әйткән болай:
— Бар, син егет, утын яр!
Хәзер үк яр, тиз бул, бар!"
Ачудан карап аска,
Егет чыккан лапаска.
Тик тапмаган бер агач,
Бер агач та булмагач,
Аптырап беткән егет,
(Тапмагач йөреп-йөреп).
Ярмаса—киселә тел,
Ярмыйча мөмкин түгел.
Шуңа, ташып оннарны,
Сүткән егет амбарны.
Егет ул көчле булган,
Арслан төсле булган.
Амбарның бүрәнәсен
Утын иткән һәммәсен...
Бай бу эшкә шак каткан,—
Инде телен шартлаткан.
Тагын үзгәрткән төсен,
Чытырдаткан ул тешен.
Алданганын аңлаган,
Тик орыша алмаган,—
(Барсын да хәтерләгән,
Тел кисүдән шүрләгән).

Икенче көн тагын бай,
Егеткә әйткән болай:
— Бар, син егет, атны җик!
Тизрәк җик! тиз бул, тик!
Ястык сал тарантаска,

Почта маркасына 100 ел

Беренче почта маркаларын 1840 нчы елда Англиядә басып чыгарганнар. Почта эшендә марка системасы бик җайлы булганга күрә, бөтен дөньядагы илләрдә дә аны бик тиз куллана башлыйлар.

Россиядә 1845 нче елда штемпель басылган конвертлар чыгарыла, ә почта маркалары аерым рәвештә бары тик 1857 нче елның декабрендә генә чыгарылалар.

Беренче почта маркаларында күбесенчә милли герблар яки бәясен күрсәткән цифрлар гына төшерелгән була.

1893 нче елда Америка Кушма Штатларында Американы ачуга 400 ел тулу уңае белән 16 төрле маркадан торган серия чыгарыла. Бу маркаларга Американы ачучы Колумбаның тормыш күренешләре төшерелгән була. Болар төрле вакыйгаларга багышланып чыгарыла торган почта маркаларының башлангычы булып торалар.

Беренче совет почта маркасы 1921 нче елда чыгарылды. Һәм аларның төре елдан-ел арта бара. Бары тик соңгы көннәрдә генә дә Маяковский, Чайковский, Тимирязевларга багышланган маркалар чыгарылды.

Бел, йомшак булсын аска,
Ачудан карап аска,
Егет чыккан лапаска.
Утырган ат каршына,
Уй йөгергән башына:
„Атларның юк карасы,
Туры да, ак барысы.
Ә бай: „Кара ат җик“,—ди,
Булмаслык эшне йөкли,
Кисәргә уйлый телне,
Тик төшермәм күңелне“,—
Дип егет гайрәтләнгән,
Хәйлә тапкан, дәртләнгән.
Җөтәнләгән ак атны,
Кигезгән дә камытны,
Җиккән ул тарантаска,.
Ястык та салган аска.
Аннан алган да дегет
Буяган атны егет.
Менә байга кара ат,
(Кап-кара ат—карап бак).
Тарантаска, атка да,
Ястыкка, камытка да,
Эшлиягә дә егет
Буяган кара дегет...
Шул чакта бай йортыннан,—
Тышкы ишек артыннан,
Егет көлү ишеткән,—
Бае чыккан ишектән.
Яңа кием киенеп,
Зур корсагын киереп,
Бай атына караган,
Аты булган карадан.
Бай төшенмичә сергә,
Хатыны белән бергә,
Тарантаска утырган,
Чәчләре үрә торган.
Җиккән ат яхшы булган,
Йөрәкле, ярсу булган,
Иөрәген кага-кага
Ыргылган ул капкага.
Егет капканы ачкан,
Ачкан да үзе качкан.
Ыргылып, нак җил кебек,
Томрылып һәм җилкенеп,
Ярсып алга чапкан ул,
Һаман йөрәк каккан ул.
Җиткәннәр алар чатка,
Бай тырышып шул чакта,
Көчкә атын туктаткан,
Булган эшкә шак каткан.
Алданганын аңлаган,
Тик орыша алмаган,—
(Барсын да хәтерләгән.
Тел кисүдән шүрләгән).

Шул чагында бар халык,
Бар урамнан җиналып,
Бай янына килгәннәр,
Килгәннәр дә көлгәннәр,
Бай халыкны орышып
Һәм таралырга кушып,
Кайтып киткән өенә,
Кабарынган көенә.
Кич җиткән—кояш баткан,
Тау артыннан—ерактан...
Бай төн булгач, тын гына
Сөйләгән хатынына:
— Тыңла, син, мине, әй дим!
Тыңла, бер киңәш әйтим:
Егет безгә бәлә бит,
Мондый егет белә бит.
Тормыш бара начарга,
Кирәк моннан качарга!
Телемне дә кисәр ул,
Башыма да җитәр ул.
Малны җыеп сандыкка,
Иортта бер кеше юкта,
Качыйк моннан еракка,
Еракка—башка якка!
Бай фикере хакында
Уен әйткән хатын да:
„Дөрес сөйлисең, картым,“—
Дип сөйләгән ул хатын...
Егет ачык ишектән
Бу сүзләрне ишеткән.
Тыңлагач яшрен генә,
Киткән ул әкрен генә...
Байлар җыйган малларны
(Калдырмыйча бар малны).
Күзәтеп йөргән егет,
Аудагы мәче кебек,
Һәм байлар өйдә юкта
Кереп яткан сандыкка...

Бай хуҗалар таң белән,
Таң белән—чулпан белән,
Ат җигеп тарантаска,
Малларны салып аска,
Сандыкны бәйләп артка,
Утырып, сугып атка,
Чыгып арттагы юлдан
Качкан алар авылдан.
Авыл калган еракта,
Урман калган бер якта.
Шатлыктан күпергән бай,
Сөйләнеп барган болай:
— Шөкер, котылдык эттән,
Эттән—явыз егеттән.
Очкан алар... шул чакта,
Артта килгән сандыкта:
—Мин мондау,—дигән егет,—

(Ерак кычкырган кебек).
Бай күзәткән як-ягын:
— Чыңлый,—дигән колагым...
Тагын кычкырган егет,—
(Юлдан йөгергән кебек).
Бай куркып һәм сөйләнеп:
— Егет куып килә,—дип,
Карамыйча артына,
Суккан тагын атына.
Ат юырткан ыргылып,
Канатланып, томрылып.
Артта калган басулар,
Чылтырап аккан сулар,
Тирбәлеп үскән гөлләр,
Тирбәнеп яткан күлләр...
Аргамактан тир аккан.
Һәм күренгән ерактан
Ялгыз йорт тау башында,
Байлар кергәннәр шунда.
Төн кунып чыгар өчен...
Атка биргәчтен печән,
Тоткадан тоткан көйгә
Сандыкны керткәч өйгә,
Ашагач күмәч һәм май,
Йоклаган хатын һәм бай...
Егет бозмый тынлыкны
Чыккан ачып сандыкны.
(Караңгы булган ул төн)
Егет салып бишмәтен
Япкан бай хатынына,
Үзе тагын тын гына,
Кигән хатын күлмәген,—
Һич берәү дә күрмәгән.
Һәм бай янына яткан,
Яткан байны уяткан.
Сөйләгән хатын кебек:
—Әй дим, килгән бит егет!“..
Бай шулчак сикереп торып,
Иләсләнеп, котырып,
Алган үткен пычакны.
Хатынын ул шул чакны
Үтерергә дип килгән.
(Егет килгән дип белгән).
Егет торып тиз генә,
Тиз генә—җитез генә,
Тартып алган шул чакны
Бай кулыннан пычакны...
Бай төшенгән барсына,
Һәм ярсына-ярсына
Хурлыгыннан орышкан,
Орышкан—кычкырышкан:
—Инде түзмим,—бел, эт син!
Эттән начар егет син!
Тагын арттан килгәнсең,
Башка бәлә икәнсең!
Бәдбәхет син, азгын син!
Азгын эттән азган син!...
Орышканга, шул төнен
Егет кискән бай телен.

1939.

I.

„Яңа юл“ колхозы табигатьнең иң матур җиренә урнашкан. Аның һәр ягы— урман һәм болыннар. Җәй көннәрендә әрәмәлектәге сандугачларның сайраулары, күкенең моңлы кычкыруы ишетелә һәм болар авылга үзенә бер төрле ям биреп торалар. Биредә урнашкан пионерлар лагерындагы балаларның иртән сигнал уйнаулары һәм көчле җырлаулары авылга тагы да ям бирә.

Әнә пионерлар Ык елгасына коенырга баралар. Алар арасында 14 яшьлек пионерка Сания дә бар. Ул VI нчы классны барлык фәннәрдән отличнога тәмамлады, аны пионер лагерына бару өчен бер айлык путевка белән бүләкләделәр.

Бай табигать кочагында, иптәшләр арасында көннәр сизелмичә генә үтеп баралар. Тиздән лагерьдан китәргә туры киләчәк. Аның иптәшләреннән аерылып өенә кайтасы килми...

Менә ул үзенең эш сөюче әнисен күз алдына китерде. Аннан аның күз алдына әтисе Сабир килеп басты. Ул әтисенә: „Әти, ник эшкә бармыйсың?“,—дип берничә мәртәбә әйткәнен хәтерләде. Сабирның тупас рәвештә генә: „Синең анда эшең юк, алдыңа куйганны аша, зурлар эшенә тыгылма!“,—дигән сүзләрен исенә төшерде.

Сабирны колхозчыларның күбесе яратмый, аны „ялкау Сабир“ дип йөртәләр. Быел ялкау Сабир үзенә бик җылы урын тапты. Ул: „Минем аягым авырта, авыр эш эшли алмыйм, мине җиңелрәк эшкә күчерсәгез иде“,—дип колхоз идарәсенә заявление бирде. Нак шул чак, ул заявление биргән көннәрдә, амбар караулчысы Гилаҗ карт бик нык авырый башлады. Колхоз идарәсе Сабирны амбар караулчысы итеп билгеләде.

Аның бу эшкә керүенә 3 ай булды. Хәзер ул тагы да ялкаулана төште. Кеше-кара күрмәгәндә төнлә амбар буенда йоклаштыра башлады, ә көндез „төне буе йокламадым“,—дип түшәктә ауный, я күрше авыл базарына барып кайта иде.

Сабир соңгы вакытларда колхоз кладовщигы Хәким белән бик дуслашып китте. Алар күп көнне икәве генә Саниялрнең келәтләрендә нәрсәләр сөйләшеп, гәпләшеп утыралар. Аларның бу эшенә Сания бик гаҗәпләнә һәм ул хәтта шикләнә дә иде. Алар келәттә утырганда ул, берәр сылтау тапкан булып, келәткә кергәләп йөри, ләкин ул керүгә әтисе тамак кырып куя һәм алар шунда ук сүзләрен туктаталар иде. Бары тик Сания аларның алларында бушаган аракы шешәсе барлыгын гына күреп чыккалый. Шуннан соң байтак вакытлар үтте, ә Сабир белән Хәкимнең җылы дуслыклары һаман дәвам итте...

II.

Сания өйләренә килеп кергәндә әнисе яңа гына эштән кайткан, ә әтисе әле йокыдан тормаган иде. Әнисе Санияне бик шатланып каршылады. Ишектән керү белән аны кочаклап алды да:

— Кызым, бигрәк тазаргансың, тагы да матурлангансың!—дип кызының тулы

һәм түгәрәк йөзенә сокланып карады. Сания әнисенә лагерьда дүрт килога артуын һәм анда бик яхшы һәм күңелле булуын сөйләде. Хәлимә апа самовар куя башлаган иде, Сания:

— Әни, үзем куярмын, син эштән арып кайткан бит,—дип үзе самовар куеп җибәрде. Хәлимә апа 45 яшьләрдә булуына карамастан, бик таза иде әле. Ул һәр вакыт эш нормасын арттырып үтәп бара, шуңа күрә Сания әнисен бик ярата һәм аңар өй эшләрендә еш кына булыша да торган иде.

Озак та үтмәде, самовар гөрләп кайнап та чыкты. Хәлимә апа Сания кайтуына дип төрле тәмле әйберләр пешереп куйган икән. Ул өстәлгә ашъяулыкны җитез генә җәйде дә, аның өстенә ашамлыклар тезеп куйды. Ул

ПВХО га хәзер!



Рәсемдә: Молотов районы № 7 мәктәпнең химия командасы (Казан шәһәре).

Фото — Л. Попов.

арада Сабир киерелә-киерелә йокысыннан уянып, урыннан торды да:

— Ник уятмадыгыз, шайтан ашыклары, караңгы төшеп килә ич!—дип җикеренергә тотынды. Санияне күреп:

— Тагы бер-ике ай торалар аны, бик тиз кайткансың, тагын шунда ятарга ярамаганмыни. Ярый, бушка ашап яткансы, минә эшкә барырсың,—дип тиргәнергә тотынган иде дә, Хәлимә апа:

— Эх, оятсыз, әллә Санияне эшкә йөртер идеңме, нинди сүз ул тагы?—дип, сорау күзе белән карады. Сабир бераз йомшаргандай булды:

— Мин аңар бүген үк эшләргә кушмыйм, ул миңа бүген кирәк әле,—диде.

Сания әтисенең бу сүзләреннән бер нәрсә дә аңламады. Чәй эчкәннән соң Сабир каравылга китте. Хәлимә апа:

— Иртә торасы бар,—дип йокларга ятты. Ә Сания шкафтан Шәриф Камалның „Матур туганда“ дигән китабын алып укырга тотынды. Йомыш белән ул чоланга чыгып кергән иде. Ләкин озак укый алмады, аның башына әллә нинди уйлар килде. Ул әнисеннән кинәт:

— Әни, әни, дим, ник безнең чоланда бодай бик күп?,—дип сорады. Хәлимә апа аның сүзләрен йокы аралаш бик үк аңлап та җиткермәде:

— Кызым, атаң алып кайтты, йокым килә,—дип әйтте дә, өстәде:

— Ят инде, кызым, сәгат 10 тула бит.

Сания лагерьда сәгат унда йоклауларын искә алып, китабын куйды да, тешләрен чистартып, урынына барып ятты. Ләкин ул тиз генә йоклый алмады.

III.

Авыл тын. Халык йоклый. Авылдагы тынлыкны гармонь уйнап, җырлап клубтан кайтучы яшьләр генә бозалар. Аларның шатлыклы җырлары авыл урамында көчле яңгырый:

— Тәрәзәмне ачып куйдым
Җәйге көннәр ямлегә,
Чәчәк аткан Совет илен
Яшәтербез мәңгегә.

Тора-бара яшьләрнең җырлары да ишетелми башлый. Бары тик этләрнең ара-тирә өреп куюлары һәм әкрен искән җил белән агач яфракларының кыштырдаулары гына ишетелә.

Менә каланча доң-доң итеп уникене сукты.

Шушы вакытта төнге караулда торучы Сабир, арткы капкадан өйләренә кайтып керде һәм әкрен генә ишек шакый башлады. Хәлимә апа аның төнлә кайтуына өйрәнгән иде инде. Шуңа күрә ул тиз генә торып ишек ачты һәм шелтәле тавыш белән:

— Тагы нишләп йөрисең инде?,— диде. Аңа каршы Сабир каты гына:

— Тик тор!,—диде дә, өйгә кереп Санияне уята башлады.

Бу вакытта Сания яңа гына йокыга киткән иде әле. Ул әтисенең тавышына куркып уянды һәм урыннан сикреп торды. Бернәрсә дә аңламыйча, одеялын башыннан ук бөркәнеп, урнына кире ятты. Сабирның йөзенә ачу чыкты, шулай булса да, ул аны сиздермәскә тырышып:

— Сания кызым, тор әле, бер җиргә барабыз, хәзер кайтабыз,—дип Санияне иркәләгән булып кыйланды. Саниянең башына әллә нинди уйлар килде. Ул нәрсә эшләргә дә белмичә, торып киенде дә:

— Кая барабыз?—дип әтисенә эндәште. Сабир аның соравын ишетмәгәнгә салышты һәм:

— Кызым, чоланнан ике буш капчык ал, әйдә, тиз бул,—диде. Сания йокы исереклеге белән чолан ишеген ача алмыйча озак кына азапланды. Чөнки аның кечкенә куллары бизгәк тоткандагы кебек калтырый, ә йөзе агарган иде. Алар өйдән чыкканда Сания әнисенең: „Тагы ниләр генә күрербез икән?..“,—дип авыр-авыр сулаганын ишетеп калды.

Сабир кечкенә арба алды. Сания юлда барганда, әтисенә бер сүз дә дәшмәде. Аның: „Эх, син, оятсыз, ник эшеңне ташлап йөрисең. Син бит колхоз милкен саклаучы!“,—дип кычкырасы килде. Ләкин түзде, алда нәрсә булачагын күрәсе килде аның. Амбар янына барып җитәрәк, Сабир:

— Кызым, менә укыр вактың җитә, сиңа яңа пальто алырмын. Яңа күлмәкләр дә алырмын. Менә нәрсә, кызым, син бераз безгә ярдәм ит инде. Син бит бик акыллы. Сиңа ул бер дә авыр түгел...

Саниянең кечкенә куллары тагы да ныграк калтырана башладылар, төсе бөтенләй үзгәрде. Ул Сабирның әйтеп бетергәнен дә көтеп тора алмады:

— Әти, син нәрсә эшләмәкче буласың?,—дип кычкырып җибәрде. Сабирның йөзенә ачу чыкты, аның сипкелле йөзе һәм озын борны Саниягә тагы да куркынычрак булып күренде. Сабир маңлаен җыерып:

— Мин, кызым, колхоз председателе кушуы буенча, амбардагы орлыклардан ике капчыкны...

Ул әйтеп бетерә дә алмады, Сания:

— Ә нигә аны көндез эшләмисез?—диюгә, Сабир катырак тавыш белән:

— Синең рәхәттә торасың килми шул, әгәр дә минем сүземә каршы торсаң, минем балам булма, өемә кайтып кермә!,—дип куркытырга тотынды.

Алар амбар янына килеп җиттеләр. Амбар янында тагы бер кеше бар иде. Караңгыда Сания аны таный алмады. Сабир тартып китергән арбасын амбар

„Икенче Баку“



Рәсемдә: Ишембай нефть промыслоларыннан № 6/20 буравая (Башкыртстан АССР).

Фото — Н. Егоров.
(ТАСС фотоклишесе).

артындагы бүрәнәләр арасына яшереп куйды да, Саниягә:

— Син менә шунда басып тор!.. Без эчкә керәбез, әгәр дә кеше килгәне күренсә, безгә әйтерсең, сак бул!,—диде. Алар эчкә кереп киттеләр.

Алдан сөйләшеп куюлары буенча, Сания кеше килгәнне күреп аларга әйтү белән үк, Сабир чыгып ишекне тыштан бикләргә һәм урнына басарга, ә теге кеше эчтә калырга, Сания амбар астына качарга тиеш иде. Саниянең йөрәге еш тибә башлады. Ул нәрсә эшләргә белмичә, аптырап калды. Аның бөтен колхозчыларга:

— Килегез, караклар бар, колхоз милкен урлыйллр. Берсе минем әти, юкла, әти түгел—колхоз милкен урлаучы ялкау Сабир,—дип кычкырасы килде. Аның күз алдына батыр пионерлар һәм пионеркалар килеп бастылар... Ул әтисе турында хәтерләде. „Әгәр дә әтине тоттырсам, әни җыларммы икән?, дип тә уйлады ул.—Юк, мин аңар аңлатырмын, ул җыламас",—дип уен икенчегә борды.

Шул вакыт әкрен генә амбар ишеге ачылды. Бер капчыкны чыгарып, арбага салдылар. Сабир белән бергә чыгучыны Сания кладовщик Хәкимгә охшатып калды. Сабир амбарга кергәндә Саниягә тагы бер мәртәбә:

— Сак бул, хәзер эш бетә,—диде. Алар амбарга кереп китвәч, Сания кыюадымнар белән амбарга таба атлады. Амбарның ишегендә ачкычы белән зур йозак эленеп тора иде. Ул аңа бераз карап торгач, йозакны кулына алды. Хәзер инде Саниянең куллары калтырамыйлар. Ул кечкенә кулларына зур йозакны тотып, аның белән ишекне бикләп, ачкычын алды да тотмасыннар дигәнсыман, бар көченә йөгерергә тотынды. Колхоз канцеляриясе урнашкан йортта ут яна. Сания әнә шул йортка таба йөгерә...

Пионер вожатые—комсомолец Заһит бүген колхоз канцеляриясендә дежур тора иде. Яктыра башлагач, тәрәзәләрне ачыйм дип, тәрәзә янына барса, ни күзе белән күрсен: капка төбендә чәчләре тузган, төсе агарган Сания басып тора иде. Заһитнең йөрәге „жу" итеп китте. Тәрәзәне ачып, йомшак кына тавыш белән:

— Сания, нәрсә булды сиңа?—дип сорады. Сания Заһитнең монда булуын күргәч, шатланып китте һәм:

— Сез биредә мени, абый?.. Сезнең янга керергә мөмкинме?.. Мин бик мөһим эш белән килдем...,—диде. Заһит:

— Мөмкин, ник мөмкин булмасын,—дигәч, Сания канцеляриягә керде дә, кулындагы зур ачкычны Заһитка сузды. Заһит аңлаша алмыйча, аптырап калды. Сания нәрсә булганын аңар яхшылап сөйләп бирде.

Колхоз милкен урлаучы Сабир белән Хәкимне тотып алып киткәндә кызарып кояш чыгып килә, колхозчылар эшкә китә башлаганнар иде инде.

Мөнҗия Гилфанова.

Казан.



Художник Г. Арсланов рәсме.



...Борны кәп-кәкре бөгелгәндер
Тәмам кармак кеби,
Төз түгел куллар, аяклар
да ботак, тармак кеби.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер
Эчкә баткан күзләре,
Кот очар күрсәң, әгәр
Төнлә түгел—көндезләре.

Яп-ялангач, нәп-нәзек;
Ләкин кеше төсле үзе,
Урта бармак буйлыгы бар
Маңгаенда мөгезе.

Кәкре түгелдер моның
Бармаклары бик төз-төзен,
Тик килешсез, һәр бере дә
Ярты аршыннан озын...

(Г. Тукай. „Шүрәле“ дән).

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ СӨЙЛИ

Безнең журналыбыз

„Пионер каләме“ журналы балалар өчен чыгарыла торган айлык әдәби журнал. Ул балаларның, укучыларның, пионерларның, хәтта кайбер зурларның да, яратып укый торган журналы.

Анда безнең әдәби иҗадыбызны үстерү өчен файдалы киңәшләр бирә торган әдәби консультацияләр дә чыга. Мәсәлән, Ә. Камал иптәшнең башлап язучыларның пьесалары турында, Г. Кутуй иптәшнең хикәяләр өстендә эшләү турында язылган әдәби консультацияләре. Мондый мәкаләләрне киләчәктә күбрәк урнаштырырга кирәк.

Бу журнал безне, әдәбият сөючеләрне, кайбер яклары белән канәгатьләндереп җиткерә алмый әле. Редакция һәр номер саен балаларның дүрт яки биш кенә шигырьләрен урнаштыру белән чикләнә. 1939—40 нчы еллар арасында чыккан номерларда балалар иҗад иткән хикәяләрнең, пьесаларның булмавы яки аз булуы—зур җитешсезлек.

Без, әдәбият сөюче яшьләр, иҗад көчләребезне үстерү өчен кирәк булган әдәби ярдәмгә мохтаж. Шуның өчен без тәҗрибәле, зур язучыларыбыздан безнең журналга үзләренең киңәшләре, фикерләре, әдәби консультацияләре белән катнашуларын сорыйбыз. Бу безгә зур ярдәм күрсәтү булыр иде.

Әгәр дә югарыда күрсәтелгән җитешсезлекләрне искә алып, „Пионер каләме“ битләрендә әдәби консультацияләргә, кече яштәге балалар өчен кызыклы әкиятләргә, шигырьләргә, яшь әдәбият көчләре тарафыннан иҗад ителгән материалларга урын кинрәк бирелсә, ул, һич шиксез, тагын да зур уңышларга ирешәчәк. Без моңа ышанабыз.

Казан, 13 нче номерлы урта мәктәпнең
әдәбият түгәрәге членнары:

Д. Зарипов,
С. Кәримов,
Б. Вафин.

Кайбер фикерләр

„Пионер каләме“—Татарстан АССР балаларының кадерле журналы. Алар аны укыйлар, аңа язышалар. Ләкин „Пионер каләме“ балаларның сорауларына җавап биреп бетерә алмый әле.

Май аеның 10 нчы числосы булуга карамастан, безнең кулда журналның март аенда чыккан 3 нче номеры гына бар. Редакция һәм типография „гаебе“ аркасында журналның һәр номеры 10—15 көнгә соңга кала. Нәтиҗәдә редакциянең яңа нәрсә дигән кайбер материаллары балаларның күптән белгән нәрсәләре булып чыга.

Безнең кулда „Пионер каләме“ нең быелгы өч номеры һәм 1939 нчы елда чыккан номерлары. Боларны карап чыккач, редакция тиешенчә эшләми әле дигән фикер туа. Менә журналның беренче номеры. Аңа кергән 22 материалның бары тик 8 е генә оригинал. Менә икенче номеры. Ә андагы 21 материалның бары тик 6 сы гына оригинал. Шуның өстенә балалар турында язылган хикәяләр, шигырьләр һәм башка материаллар аз.

Үзенең күләме кечкенә булу нәтиҗәсендә, „Пионер каләме“ хронологик журнал формасындарак чыга. Ул бик күп төрле материал җыеп, аларга аз-аз урын бирә. Шуңа күрә теге яки бу вакыйга турында зур яштәге балаларның соравына тулысынча җавап бирә алмый.

Мәктәпкәчә яштәге балалар өчен, октябрятләр өчен, татарча журнал чыгарылмый. Шуңа карамастан, „Пионер каләме“ нәниләр өчен язылган әсәрләргә бик аз урын бирә. Моннан соң һәр номерда октябрятләргә югары художестволы әсәрләр, уеннар биреп баруны булдырырга кирәк.

Укучылар журнал битләрендә киләчәктә тагын да югарырак сыйфатлы, художестволы әсәрләр һәм башка материаллар бирелер дип көтеп калалар

Ж. ТӘРҖЕМАНОВ.

ДАҺИ РУС КОМПОЗИТОРЫ

(П. И. Чайковскийнең тууына 100 ел тулды)

Бөек рус композиторы, Петр Ильич Чайковский, 1840 нчы елда Уралдагы Воткинск шәһәрендә туды. Аның балалык чаклары Удмуртиянең гүзәл табигате эчендә, үзенең атасы, завод директоры, Илья Петрович Чайковскийнең зур өендә үтте.

Чайковскийләр семьясендә дуслык һәм мәхәббәт атмосферасы хөкем сөрде. Атасының артык дәрәҗәдә йомшак күңелле булуы, фортепианода яхшы уйнаучы һәм матур тавышка ия булган анасының талантлылыгы, тормыш шартларының тынычлыгы—менә болар барсы да даһи талантлы баланың нормаль үсүен тәэмин иттеләр. Алар композиторның хәтерендә соңгы көннәренә кадәр сакландылар.

Чайковский үзенең балалык чорында гадәттән тыш тиз тәэсирләнүчән була: аны ул вакытта „пияла бала“ дип атыйлар. Ул биш яшенә җиткәч үк музыкадан дәресләр ала башлый һәм бу өлкәдә искиткеч уңышларга ирешә. Җиде яш тулганда инде ул Шопен мазуркасын бик яхшы итеп уйный.

Чайковскийга 8 яш тулгач, алар Петербургка күчеп киләләр. Киләчәктә композитор булачак кеше, Петербургтагы хокук белеме мәктәбенә кереп, анда тугыз ел укый. Бу вакыт ул сәнгат эшләре белән шөгылләнергә мөмкинлек бирми торган тупас һәм хәрәкәтсезлек—ялкаулык средасы эчендә вактын үткәрә. Чайковский бу елларда әле музыка өлкәсендә эшләү турына уйламый да. Ләкин шулай да, бу вакыт ул фортепианода уйнауда зур осталыкка ирешә.

Петр Ильич, 1859 нчы елда хокук белеме мәктәбен тәмамлый. Ул аннан, үзе әйтүенчә, „начар чиновник“ булып чыга. Ул юстиция министерлеге департаменты буенча хезмәттә саналып, буш вакытларын күңел ачып үткәрә. Ләкин тиздән даһи музыкантның тирән натурасы өстенлек ала: егерме ике яшьлек Чайковский музыка өлкәсендә ныклы рәвештә эшләргә карар бирә. Ул үзен туйдырган департаменттагы хезмәтне ташлый. Һәм Петербургта консерватория ачылу белән, Антон Рубинштейнның композиторлык классына укучы булып керә. Яш композитор укыган вакытта искиткеч сәләтлелек күрсәтә.

Чайковский дәресләр бирүдән килгән акча хисабына яши. Шул ук вакытта ул йөзләрчә музыкаль упражнение һәм әсәрләр яза. Шулар эчендә Островскийнең „Гроза“ исемле әсәренә увертюра, ике симфоник увертюра, кыллы квартет һәм Шиллерның „Шатлыкка“ исемле әсәренә музыкалар яза.

Чайковский 1865 нче елның декабрендә консерваторияне тәмамлый. Москвага күчеп килә һәм анда яңа гына ачылган консерваториягә профессор булып билгеләнә. Чайковский Москвада унике ел тора. Педагогик эш белән бергә, иҗад эшен дә киң җәелдерә. Шул вакыт эчендә ул: „Воевода“, „Ундина“, „Опричник“, „Кузнец Вакула“, „Евгений Онегин“ операсын, Островскийнең „Снегурочка“ исемле пьесасына музыка, „Лебединое озеро“ балетын, беренче дүрт симфонияне, „Ромео һәм Джульетта“, „Буря“, „Франческа де-Кимени“ симфоник поэмаларын, беренче фортепиано концерты, романслар һәм башка бик күп әсәрләр яза. Шул ук вакытта Петр Ильич музыка турында талантлы фельетоннар бастырып чыгара, музыкада итальянчылыкның өстенлек тотуына каршы чыгып, рус милли сәнгатен яклый, Балакиров һәм Римский-Корсаков әсәрләрен киң таратырга өнди.

Петр Ильичнең Москвада иҗад ителгән әсәрләренең төп характеры—аларның моңлы, матур лирикалы булуында. Шуның белән бергә, аларда көчле драматизм бар. Операларына караганда, оркестр өчен язылган әсәрләрендә дә бу ныграк сизелә. Композитор рус һәм украин халык җырларын үзенең операларында һәм уен кораллары өчен язылган әсәрләрендә киң рәвештә файдалана.

Чайковский яш вактында ук инде халык арасында шактый зур популярлыкка ирешә, ләкин

профессиональ критиканың күп өлеше аның уйларын аңлый алмый.

Чайковский Москвада торганда материаль яктан бик авыр хәлдә яши.

Чайковский үзенең әсәрләре турындагы уңышсыз отзывларга артык дәрәҗәдә тәэсирләнүчән була. Шундый настроениеләр йогынтысында ул кайбер әсәрләрен юк итә.

Чайковскийнең Москвада танышлары бик күп була. Ул Достоевский, петрашевчылар, шагыйрь Плещеев, язучы Островский һәм алдынгы интеллигенциянең башка вәкилләре белән еш очраша.

Петр Ильичнең шәхси тормышы уңышсыз була. Ул вактын ялгызлыкта, һәр вакытта иң авыр хезмәт өстендә һәм шуның белән бергә материаль яктан начар шартлар эчендә үткәрә. Менә болар барсы да, өзлексез авыр эшләр белән шөгыльләнгән һәм шуның аркасында чамадан тыш арган Петр Ильичнең нерваларын бик нык какшаталар Шуңа күрә ул, педагогик эшен ташлап, чит илгә китәргә мәҗбүр була.

Чайковский иҗад тормышының икенче яртысында да үзенең искиткеч активлыгын югалтмады. Бу чорда ул: „Орлеанская дева“, „Мазепа“ „Чародейка“, „Пиковая дама“, „Иоланта“ операларын, „Спящая красавица“, „Шелкунчик“ балетларын, бишенче, алтынчы һәм „Манфред“ симфонияләрен һәм башка әсәрләрен язды.

Петр Ильичнең тормышы искиткеч дәрәҗәдә күп көч куела торган хезмәт өстендә үтте. Шул ук вакытта аңар бер шәһәрдән икенче шәһәргә, бер илдән икенче илгә күчеп йөрергә туры килде, Чөнки аңар репетицияләрдә, концертларда һәм спектакльләрдә булырга, үз әсәрләренең дөрес башкарылуы өчен көрәшергә, хәтта, дирежерлык ролен үтәргә дә туры килә иде.

Чайковский үзенең яшәү вактында ук бөтен дөнья күләмендә дан казанды. Аның Берлиндә, Прага, Париж, Лондон, Нью-Йорктагы гастрольләре бик уңышлы үтте. Кембридж университеты аңар „музыка докторы“ дигән исем бирде. Филармония җәмгыятьләре аны почетлы член итеп сайладылар.

Рус матбугатының реакцион өлеше рус музыкасының иң бөек талантына каршы үзенең дошманлык чыгышын көчәйтте. Тыңлаучыларның киң катлавы арасында Чайковскийнең әсәрләре киң җәелгән иде. Хәсрәт критикларның ачулы тавышлары, Чайковский чыгышларына карата булган шау-шулы алкышлар дингезендә бөтенләйгә күмелеп, юк булып калалар иде. Чайковский җитәкчелегендә бишенче симфония беренче тапкыр башкарылганнан соң, тыңлаучылар аны егерме дүрт тапкыр алкышлап чакыралар. Ләкин бөек художник үз-үзенә нык критика ясау сәләтлелеген һич кайда һәм һичбер вакытта да югалтмады. Әгәр ул, теге яки бу әсәрнең өстенлегенә ышанмаса, башкаларның мактавына әһәмият бирми иде.

Чайковскийнең композиторлык хезмәтенең темплары кайчакта артык кызу булып, аңа ирешү мөмкин булмаган эшкә әверелә иде. Мәсәлән, ул „Пиковая дама“ ны кырык дүрт көндә язып бетерде.

Чайковский үзенең характерындагы яхшы сыйфатлар белән башкалардан аерыла. Ул кешеләр белән аралашканда аларга карата яхшы һәм турыдан-туры мөнасәбәттә була. Үзенә үтенеч белән мөраҗәгать итүчеләргә сизгерлек һәм игтибарлылык күрсәтә. Ул һәр вакыт берәр кешенең эше артыннан йөри, укучы яшьләргә булыша, Клин крестьяннәренә материаль ярдәм күрсәтә. Ул, шулай ук, Клиндә мәктәп ачтыру һәм шуның кебек башка эшләрне үтәргә дә ирешә.

Чайковский Петербургта, 1893 нче елда, үзенең алтынчы симфониясен үз җитәкчелеге астында башкарды. Шуннан берничә көн үткәч, ноябрьнең бишендә, төнлә белән, иҗад көченең тулысынча чәчәк ату вактында, ул кинәт үлеп китте.

Революциядән соң Чайковскийнең музыкасы бөтен хезмәт ияләренең байлыгы булып әверелде. Азат ителгән халык композиторга дөрес бәя бирде һәм аны яратты. Миллионнарча тыңлаучылар, үзе яшәгән чорны, аның иң яхшы омтылышларын тулысы белән аңлаткан бөек композиторның әсәрләрен шатлыклы тойгы белән үзләштерәләр. Аның әсәрләрендә, көрәш һәм газап чигү аша киләчәккә якты ышаныч, азат ителгән кешелек дөньясына һәм бәхетле, тулы кыйммәтле кеше шәхсенә ышану ачык гәүдәләнеп тора.

Композитор *Җәүдәт Фәйзи.*

Җаваплы редактор **Г. ХӘБИБУЛЛИН.**

Ответств. редактор **Г. ХАБИБУЛЛИН.**

Заказ № 2028. 2 табак. Табакта 70.700 знак. Главлит вәкиле № 165. Производствога бирелде 7/V—40 ел. Басарга кул куелды 28/V—40 ел. Тираж 6176. Кәгаз форматы 70×108.

Н. Александров исемендәге типография. Казан, Бауман урамы, 19. 1940 ел.

КҮҢЕЛЛЕ ЯЛ

Куйбышев шәһәре пионерлар дворецының автомотокабинетында мотоциклет өйрәнәләр.
Фото—П. Щукин. (ТАСС фотоклишесе).

ШАРАДА

Беренче иҗеге аның
Кыш көннәрендә була.

Кыр, урманнар барсы да
Шул нәрсә белән тула.

Икенчесе җәй көнендә
Төннәрен җиргә төшә,

Кояш көлеп карау белән
Һавага очып бетә.

Күп өйләрдән, күп семьядән
Мөмкин аны табарга.

Һәр җирдә дә бәхет, шатлык
Хөрмәт табыла аларга.

Ш. Сөләйманов.
Челябе өлкәсе.

ЦИФРЛАР

Берсеннән берсе бер (1) берәмлеккә зур булган өч саннан икенчесенең квадратлар суммасы өченчесенең квадратына тигез була.

Болар нинди саннар, дөресрәге нинди цифрлар?

УЛ КЕМ?

Бер кеше урамнан үтеп барганда кечкенә генә өй янына басып торучы кешене күреп:

„Нигә биредә торасың?“ дип сораган. Теге кеше:

„Мин әтинең өен саклыйм, ләкин мин аның улы түгел“,—дип җавап биргән.

Сезнеңчә бу кем булыр?

ШАРАДАЛАР

1. Үзе биш хәрефтән тора торган сүз. Баштагы өч хәрефен генә укысаң татлы әйбер исме килеп чыга. Соңгы ике хәрефе Татарстандагы елга исме. Барсы бергә—суда яшәүче, бик тиз йөзүче.

2. Барсы биш хәрефтән тора. Баштагы өч хәрефе—сыер бирә торган продуктның берсе, соңгы ике хәрефе әйбернең төсен аңлата. Барсы бергә—юл читенә кадалган әйбер.

М. Гәрәев.
Казан шәһәре.

УЙЛАП ТАП

Беренче иҗеге—хәйван.
Икенче иҗеге—сыйфат.
Икесе бергә—карт кешеләр тотып йөри торган әйбер.
Беренче иҗеге—хәйван.
Икенче иҗеге—бойрык фигыл.
Икесе бергә—кош исме.

Сәет Хамәдиев.
Аксубай районы, „Батыр“ колхозы.

МЕТАГРАММА

1. „С“ белән—хөкем итү урны.
„Ч“ белән—күл исме.
2. „П“ белән—сугыш коралы.
„К“ белән — СССР ның көньягындагы шәһәр.
„М“ белән—винтовканың бер часте.

Зиннур Ибраһимов.
Кукмара районы, Мәчкәрә урта мәктәбе.

БӘЯСЕ 50 ТИЕН
ЦЕНА 50 КОП.

ВЛКСМ НЫҢ ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН МӘГАРИФ ХАЛЫК КОМИССАРИАТЫ

ОРГАНЫ

„ПИОНЕР КАЛӘМЕ“

журналына 1940 нчы ел өчен

ПОДПИСКА АЛУ ДӘВАМ ИТӘ

„ПИОНЕР КАЛӘМЕ“—

БАЛАЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН АЙЛЫК ӘДӘБИ ЖУРНАЛ.

ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:

12 айга 6 сум.
6 „ 3 „
3 „ 1 „ 50 тиен.
Аерым саны 50 „

Журнал үз вактында һәм тәртипле рәвештә килсен өчен 1940 нчы елның калган айларына, озаграк срокка язылу яхшырак.

ПОДПИСКА БАРЛЫК ПОЧТА БҮЛЕКЛӘРЕНДӘ, ХАТ ЙӨРТҮЧЕЛӘРДӘ ҺӘМ СОЮЗПЕЧАТЬТӘ **АЛЫНА**

„ПИОНЕР КАЛЯМЕ“

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ ЖУРНАЛ ПИОНЕРОВ И ШКОЛЬНИКОВ

ОРГАН ОБКОМА ВЛКСМ И НАРКОМПРОСА ТАССР.